# Һәрбер мөселманга тиешле
# ДӨРЕС ИНАНУЛАР

Шәех Гәбдүссәләм ибн Бәрҗис ибн Гәбдүлкәрим

رحمه الله تعالى

*Гарәпчәдән тәрҗемә (кайбер кыскартулар белән)*

# ЭЧТӘЛЕК

**Тәрҗемәчедән кереш сүз** ........ 3
**Автордан кереш сүз** ........ 4
**Аллаһның бердәнбер галәмнәр Раббысы булуына карата дөрес инану** ........ 7
**Аллаһның исем-сыйфатларына карата дөрес инану** ........ 10
**Аллаһның бердәнбер гыйбадәткә лаеклы Зат булуына карата дөрес инану** ........ 12
**Иманның алты нигезенә карата дөрес инану** ........ 17
***Аллаһка иман*** ........ 17
***Фәрештәләргә иман*** ........ 17
***Күктән иңдерелгән Изге Китапларга иман*** ........ 20
***Аллаһ Тәгаләнең рәсүлләренә иман*** ........ 23
***Кыямәт көненә иман*** ........ 27
***Тәкъдирнең яхшысына да, яманына да иман*** ........ 29
**Иманның асылына карата дөрес инану** ........ 33
**Олы гөнаһлар кылучыларның хөкеменә карата дөрес инану** ........ 36
**Пәйгамбәребезнең ﷺ сахабәләренә карата дөрес инану** ........ 39
**Пәйгамбәребезнең ﷺ гаилә әһелләренә (әһлү-л-бәйт) карата дөрес инану** ........ 42
**Әүлияләр белән булучы гадәттән тыш хәлләргә карата дөрес инану** ........ 44
**Мөселманнарның дәүләт башлыклары каршында булган вазифаларга карата дөрес инану** ........ 45
**Дини мәсьәләләрдә низаг һәм тартышуның тыелганлыгы** ........ 47
**Үз теләкләренә иярүчеләр белән бергә утыру хакында кисәтү** ........ 49

## **Тәрҗемәчедән кереш сүз.**

**БисмиЛләһи-р-Рахмәәни-р-Рахиим.**

(Рәхмәт иясе һәм Рәхимле булган Аллаһ исеме белән!)

Барча мактау Аллаһ Тәгаләгә тиешле! Без Аңа шөкер кылабыз, Аннан ярдәм сорыйбыз, Аның ярлыкавын үтенәбез! Нәфсебезнең начарлыгыннан, бозык гамәлләребездән Аллаһ Тәгаләдә сыену эзлибез!

Кемне Аллаһ туры юлга күндерсә, аны беркем дә адаштырмас, ә кемне адаштырса – беркем дә туры юлга күндерә алмас. Шәһадәт бирәмен – Аллаһтан башка гыйбадәткә лаеклы һичбер илаһ юк, Ул берүзе, тиңдәшсез һәм шәһадәт бирәмен – Мөхәммәд Аллаһның колы һәм илчесе!

Кадерле укучы! Әлеге “Һәрбер мөселманга тиешле дөрес инанулар” дип исемләнгән китапчыкта Ислам диненең нигезен тәшкил итүче мәгълүмат китерелә. Әлеге мәгълүмат, дәлилләр белән ныгытылып, кыскача бирелгән. Аның авторы хәзерге заманның билгеле галиме шәех Гәбдүссәләм ибн Бәрҗис ибн Гәбдүлкәрим. Һиҗри исәп буенча 1387 елда (милади буенча 1967-нче ел) туган, үзенең җирлегендә зур галимнәрдән белем алган. Шәех – билгеле һәм файдалы китаплар авторы (беренче китабын 18 яше тулганчы ук язган), мәхкәмә (суд) институтында мөгаллим вазыйфасын башкарган, гыйлем таратып төрле илләрдә вәгазь һәм дәресләр биргән. Күркәм әхлаклы, йомшак, тыйнак, шуның өстенә оста шагыйрь дә булган, туганнары белән кайчак шигъри юллар белән сөйләшергә яраткан. Шәех Гәбдүссәләм һиҗри исәп белән 1425 елда (милади буенча 2005 елда) 38 яшендә юл һәлакәтендә вафат була. Аллаһ аңа рәхимле булсын!

[Тәрҗемә, төп мәгънәсен югалтмыйча, бераз кыскартулар белән бирелде. Кайсыбер төшенчәләргә ачыклык кертү өчен тәрҗемәчедән сылтамалар куелды].

## Автордан кереш сүз.

**БисмиЛләһи-р-Рахмәәни-р-Рахиим.**

(Рәхмәт иясе һәм Рәхимле булган Аллаһ исеме белән!)

Аллаһка барча мактаулар һәм Аллаһ илчесе Мөхәммәдкә, аның гаилә әһелләренә һәм барча сахабәләренә Аллаһның салаваты һәм сәламе булсын.

Һәм аннан соң:

Сөннәт һәм Җәмәгать әһелләренең (Әһлү-с-Сүннәти үәл-Җәмәга) игътикады [1] – һәрбер мөселманга тиешле булган хак дин буладыр, чөнки ул – пәйгамбәребез Мөхәммәднең ﷺ [2], аның игелекле һәм күркәм сахабәләренең (Аллаһ алардан разый булсын) игътикады. Әгәр дә берәр кем бу игътикадка карыша икән – ул үзен Аллаһ Тәгаләнең каты җәзасына, нәфрәтенә һәм ачуына дучар итә.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд ﷺ үзенең өммәтендә төрле агымнар һәм фиркалар булачагын алдан кисәтеп куйды, аларның саны җитмеш өч булачак диде һәм әйтте: ***"Барысы да Утта булыр, бары берсеннән кала, һәм алар – әл-җәмәга".*** Бу хәдисне Мөгәвия رضي الله عنه [3] исемле сахабәдән имам Әхмәд һәм Әбү Дәүд, Әнәс رضي الله عنه исемле сахабәдән Әхмәд, Ибн Мәҗәһ һәм Ибн Әби Гәсыйм китерәләр.

Уттан имин булачак әлеге "әл-җәмәга"не пәйгамбәребез ﷺ сыйфатлап күрсәтте: ***"Алар – бүгенге көндә мин һәм минем сахабәләрем юлында булучылар"*** – диде. Хәдисне имам әл-Әҗүрри үзенең "Әш-Шәрига" китабында Гәбдуллаһ ибн Гәмер رضي الله عنهما исемле сахабәдән, имам әт-Табарани "Әс-Сагыйр" һәм "Әл-Әүсат" китапларында Әнәс ибн Мәликтән رضي الله عنه китерәләр.

Ягъни, Сөннәт һәм Җәмәгать әһелләренең ачык билгесе булып – пәйгамбәребезнең ﷺ Сөннәтенә һәм аның тугры хәлифләренең юлына, хәтта хәдистә әйтелгәнчә ***"урт тешләре белән тешләп"*** ябышкан кебек, ныклап иярү тора. [4] Шуңа күрә, алар – "әл-фиркатү-н-нәҗия", ягъни "газаптан котылган төркем" – Кыямәт көнендә Уттан котылучылар, бу дөньяда – бидгать [5] гамәлләрдән имин булучылар. Шулай ук, алар "әл-фиркатү-л-мәнсура", ягъни "ярдәмле, җиңүчән төркем", чөнки пәйгамбәребез ﷺ бер хәдисендә алар турында: ***"Минем өммәтемдә бер төркем ачык юлда булудан туктамас, һәм Аллаһның әмере килгәндә алар шул юлда булырлар"*** – дигән. Хәдисне

---

[1] "Игътикад" – дини ышанулар.

[2] "Аллаһның аңа мактавы һәм сәламе булсын" дигән мәгънәдәге сүзләр.

[3] "Аллаһ аңардан разый булсын" дигән мәгънәдәге сүзләр.

[4] Әл-Гирбад ибн Сәрия رضي الله عنه исемле сахабәдән хәбәр ителә, Аллаһ илчесе ﷺ әйткән: ***"Чынлыкта, сезнең кайсыгыз озын гомер кичерсә, шул бик күп фикер каршылыклары күрер. Шуңа күрә, минем Сөннәтемә һәм туры юлдан баручы хәлифләремнең юлына иярегез, хәтта, урт тешләрегез белән [шул юлга] ябышыгыз һәм дингә төрле яңалыклар кертүдән сакланыгыз. Чынлыкта, һәрбер яңалык – адашудыр!".*** Әбү Дәүд 4607, әт-Тирмизи 2676, Ибн Мәҗәһ 42, Ибн Наср 21. Хәдиснең дөреслеген имам әт-Тирмизи, әл-Бәззар, әл-Хәким, Ибн Гәбдүлбәрр, әд-Дыя әл-Мәкъдиси һ.б. расладылар.

[5] "Бидгать" – Аллаһка гыйбадәт кылу нияте белән дингә төрле яңалыклар кертү.

имам әл-Бохари һәм Мөслим үзләренең “Сахих” хәдисләр җыентыкларында Әл-Мүгъира ибн Шүгбә رضي الله عنه исемле сахабәдән китерәләр.

“Ачык юлда” дигән сүзләр “ярдәмле, җиңүче” мәгънәсендә килә, мисал өчен Аллаһ Тәгалә Көръәндә әйтә: **“Иман китергән таифәгә дошманнарын җиңеп өстен булырга куәт вә ярдәм бирдек, һәм алар өскә чыгып ачык юлда булдылар”.** (“Әс-Сафф” сүрәсе, 14-нче аять). Шулай ук: **“Чынлыкта, Безнең гаскәребездер, алар, әлбәттә, дошманнарын җиңерләр”.** (“Әс-Саффәт” сүрәсе, 173-нче аять).

Һәм алар – бербөтен, ягъни аерым тармакларга таркалмаган төркем, шуңа күрә дә “әл-җәмәгә” дип йөртеләләр. Аллаһ Тәгалә әйтте: **“Инде хакны ташлаганнан соң, адашудан башка нәрсә булыр?!”** (“Йуныс” сүрәсе, 32-нче аять).

Аларның “Ислам”, “Сөннәт” һәм шул сүзләргә күрсәтүче исемнәрдән кала башка атамалары юк. Имам Мәлик رحمه الله әйткән: *“Сөннәт әһелләренең билгеләп торучы ниндидер атамалары юк, алар җәһмий*[6] *дә, кадарий*[7] *да, рафидый*[8] *да түгелләр”* – дигән.

Тәкъва сәләфләр (әс-сәләф әс-салих)[9] игътикадын саклау һәм ныгыту, дәлилләрен китерү һәм аңлату нияте белән бертөркем бөек имамнар күп китаплар яздылар, кайсыларында игътикадка карата аерым бүлекләр бирделәр, кайсыларын аерым шушы темага гына багышладылар. Бу китапларны “игътикад” мәгънәсендә “Әс-Сөннәт” һ.б. шундый исемнәр белән атадылар, аларның гомуми саны 250 дән артып китә, мисал өчен кайберләре:

- “Әс-Сөннәт” – Ибн Әби Шәйбә;
- “Әс-Сөннәт” – Әхмәд ибн Хәнбәл;
- “Әс-Сөннәт” – Ибн Әби Гәсыйм;
- “Әс-Сөннәт” – Гәбдуллаһ ибн Әхмәд;
- “Әс-Сөннәт” – Әл-Халләл;
- “Әс-Сөннәт” – Әхмәд ибнүл-Фүрат Әби Мәсгүд әр-Рази;
- “Әс-Сөннәт” – Әсәд ибн Мүсә;
- “Әс-Сөннәт” – Ибнүл-Къасим;
- “Әс-Сөннәт” – Мөхәммәд ибн Сәләм әл-Бикәнди;
- “Әс-Сыйфат һәм җәһмийләрне инкяр итү” – Нүгәйм ибн Хәммәд;
- “Әс-Сөннәт” – Әл-Әсрам;
- “Әс-Сөннәт” – Хәрб ибн Исмәгыйль әл-Кирмәни;

---

6 “Җәһмийләр” – Аллаһ Тәгаләнең исем-сыйфатларын инкяр итүче кәләм (фәлсәфә) агымы.

7 “Кадарийлар” – Аллаһ Тәгаләнең гыйлемен һәм тәкъдирен инкяр итүче кәләм (фәлсәфә) агымы.

8 “Рафидыйлар” – пәйгамбәребезнең ﷺ сахабәләренең күпчелеген көферлектә гаепләүче шигыйлар агымы.

9 “Сәләфләр” – пәйгамбәребез ﷺ һәм аның сахабәләре, алардан соң килгән тәбигыйннәр, һәм алардан соң килгәннәр, ягъни беренче өч буын мөселманнар. Пәйгамбәребез ﷺ: ***“Иң хәерле кешеләр – минем буын, аннан алардан соң килүчеләр, аннан боларыннан соң килүчеләр”*** – дигән. (Әл-Бохари һәм Мөслим китерәләр).

- “Әс-Сөннәт” – Ибн Әби Хәтим;
- “Әс-Сөннәт” – Ибн Әби-д-Дүньйә;
- “Әс-Сөннәт” – Ибн Җәрир әт-Табари;
- “Дин нигезләрен аңлату” – шулай ук Ибн Җәрир әт-Табари;
- “Әс-Сөннәт” – Әт-Табарани;
- “Әс-Сөннәт” – Әбү-ш-Шәех әл-Әсбаһәни;
- “Әс-Сөннәт” – Әбү-л-Къасим әл-Ләләкәи;
- “Әс-Сөннәт” – Мөхәммәд ибн Наср әл-Мәрүәзи;
- “Сәләфләрнең һәм хәдис тарафдарларының гәкыйдәсе” – Әс-Сабуни;
- “Әл-Ибәнә” – Ибн Бәтта;
- “Әт-Тәүхид” – Ибн Хузәймә;
- “Әт-Тәүхид” – Ибн Мәндәһ;
- “Әл-Иман” – Ибн Әби Шәйбә;
- “Әл-Иман” – Әбү Гүбәйд әл-Къасим ибн Сәлләм;
- “Сөннәт шәрхе” – Әл-Мүзәни;
- “Сөннәт әһелләре мәзхәбләре шәрхе” – Ибн Шәһин;
- “Сөннәт әһелләренең гәкыйдәсе” – Әбү-л-Къасим әл-Әсбаһәни;
- “Сөннәт нигезләре” – Ибн Әби Зәмәнин;
- “Әш-Шәрига” – Әл-Әҗүрри;
- “Сөннәт әһелләренең игътикады” – Әбү Бәкер әл-Исмәгили;
- “Әс-Сөннәт” – Әл-Бәрбәһәри;
- “Әл-Иман” – Ибн Мәндәһ;
- “Әл-Иман” – Әл-Гәдәни;
- “Әл-Гареш” – Мөхәммәд ибн Әби Шәйбә;
- “Әл-Къадр” – Ибн Үәһб;
- “Әл-Къадр” – Әбү Дәүд;
- “Әр-Руйә”, “Әс-Сыфат”, “Ән-Нүзүл” – Әд-Дәракъутни һ.б. бик күп китаплар и рисаләләр.

Шулай ук, әлеге санап үтелгән имамнардан соң килгән Сөннәт әһелләре галимнәренең китапларын да искә алырга кирәк, шулардан – Ибн Гәбдүлбәрр, Гәбдүлгъани әл-Мәкъдиси, Ибн Къудәмә әл-Мәкъдиси, Ибн Тәймийә, Ибн әл-Къаййим, Әз-Зәһәби, Ибн Кәсир, Мөхәммәд әт-Тәмими һ.б. китаплары. Аларның китапларында дөрес игътикад, шуңа дәлилләр китерү һәм үз теләкләренә иярүчеләрнең шик-шөбһәләрен инкяр итү урын алган.

Без дә, кыскача гына, әлеге күркәм кавем игътикадының күпмедер өлешен искәртеп узырбыз. Ә тәүфыйк – Аллаһтан гына, Аңа гына тәвәккәл кылдым һәм юнәлдем!

**<u>Аллаһның бердәнбер галәмнәр Раббысы булуына карата дөрес инану.</u>**

Сөннәт һәм Җәмәгать әһелләре Аллаһ Тәгалә бердәнбер бар кылучы, барча мәхлукатның [10] бердәнбер хуҗасы һәм барча галәмнәрнең бердәнбер идарәчесе икәнлегенә инанганнар.

Аллаһ Тәгалә әйтте: **“Чынлыкта, Раббыгыз – Аллаһ алты көн эчендә җирне вә күкләрне төзеде, аннан Гарешкә күтәрелде. Аллаһ Тәгалә төн караңгысы белән көнне каплар, ул төн көнне ашыгып алыштырыр, ягъни туктамыйча бер-бер артлы килеп торырлар. Кояш, Ай вә йолдызлар Аллаһ әмере буенча йөриләр. Бары Ул гына барча нәрсәне бар кылды һәм барчалык белән идарә итә. Галәмнәр Раббысы Аллаһ бәрәкәт Ияседер”.** (“Әл-Әграф” сүрәсе, 54-нче аять).

Аллаһ Тәгалә, шулай ук, әйтте: **“Бары Аллаһка гына җир вә күкләрнең мөлке хастыр, Үзе теләгән нәрсәләрне бар кылыр”.** (“Әш-Шүра” сүрәсе, 49-нчы аять).

Шулай ук, Аллаһ әйтте: **“Бары Аңа гына җир вә күкләр патшалыгы, Ул тергезә һәм вафат кыла, вә Ул – Аллаһ һәр нәрсәгә көче җитүчедер”.** (“Әл-Хәдид” сүрәсе, 2-нче аять).

Тәүхиднең [11] бу төре – “тәүхид әр-рубүбийә” – кешеләрнең күңелләренә салынган һәм урнаштырылган. Шуңа күрә, мөэмин-мөселман булсынмы, яки имансыз булсынмы, бер кеше дә бу мәсьәләгә карата низагка керми. Аллаһ Тәгалә Көръәндә әйткәнчә: **“Әгәр син алардан җирне вә күкләрне кем бар кылды һәм Кояшны вә Айны кем буйсындырды дип сорасаң, әлбәттә – Аллаһ диярләр”.** (“Әл-Гәнкәбүт” сүрәсе, 61-нче аять).

Шулай ук, Аллаһ Тәгалә имансызлар турында әйтте: **“Аларның күбрәге Аллаһка ширек [12] кылган хәлләрендә ышанырлар”.** (“Йосыф” сүрәсе, 106-нчы аять). Имам Мөҗәһид رحمه الله әйткән: *“Аларның иманнары – “Аллаһ безне бар кылды, ризыкландыра һәм вафат кыла” дигән сүзләре. Әмма, шул ук вакытта, алар үзләренең гыйбадәтләрен башкаларга юнәлтеп, ширек гамәлләре кылалар”* – дигән.

Мөшрикләрнең [13] Аллаһтан кала башкаларга гыйбадәт кылуларының сәбәбе үзләренең гыйбадәт кыла торган затларын Аллаһ кебек барча нәрсәне бар кылучы дип ышануларында булмаган. Бәлки алар, бар итү сыйфаты – Бер Аллаһ Тәгаләгә генә хас булуын таныганнар, әмма ширек гамәлләренең сәбәбе – шул гыйбадәт кыла торган затларын Аллаһ белән үзләре арасында арадашчы, Аллаһка якынайтучы һәм Аның каршында шәфәгатьче итеп алуларында булган. Аллаһ Тәгалә әйтте: **“Ширектән һәм риядән пакъ булган дин – Аллаһка гынадыр. Аллаһтан башкаларны яклаучы итеп алган мөшрикләр [әйтәләр]: “Без аларга гыйбадәт кылабыз – бары безне Аллаһка якынайтсыннар өчен генә”.** (“Әз-Зүмар” сүрәсе, 3-нче аять).

---

10 Аллаһ бар кылган тере яки җансыз булган барча нәрсәләр бер сүз белән “мәхлукат” дип әйтелә.

11 Тәүхид – бериләһлек.

12 Ширек – күпиләһлек, Аллаһ Тәгаләгә кемне яки нәрсәне булса да тиңләү, Аның белән беррәттән башкаларга гыйбадәтләрне юнәлтү.

13 Мөшрик – ширек кылучы, Аллаһ белән беррәттән башкаларга гыйбадәт кылучы.

Шулай ук, Аллаһ әйтте: **“Мөшрикләргә әйт: “Күрәсезме, Аллаһтан башка иләһ итеп алган затларыгызны – алар җир өстендә нәрсә бар кылдылар, миңа күрсәтегез!” Әллә аларның күкләр милкендә нинди дә өлешләре бармы?! Яки Без аларга Аллаһның тиңдәше бар дип өйрәткән китап иңдердекме, үзләренә шул китаптан ачык аңлатмалар алаларм ы? Залимнәр бер-берләренә бары [матур булып күренгән] алдау сүзләре белән генә вәгъдә бирерләр”.** (“Фәтыр” сүрәсе, 40-нчы аять).

Шулай ук, Аллаһ Тәгалә Көрайш мөшрикләре турында әйтте: **“Аларга, дөреслектә, Аллаһтан башка хак иләһ юк, мәгәр Аллаһ Тәгалә Үзе генә дип әйтелсә, алар Аллаһны берләүдән тәкәбберләнәләр. Вә әйтәләр: “Электән бирле гыйбадәт итеп килгән затларыбызны бер җенләнгән шагыйрь сүзенә карап ташлыйкмы?””** (“Әс-Саффәт” сүрәсе, 35-36 нчы аятьләр).

Аллаһ Тәгалә, шулай ук, аларның сүзләрен китерде: **“Ул безнең күп иләһләребезне бетереп, бер Аллаһка гына гыйбадәт кылырга әмер итәме? Аның бу гамәле шиксез гаҗәп эштер”.** (“Сад” сүрәсе, 5-нче аять).

Шуңа күрә, тәүхиднең бу төрен – Үзенең бердәнбер галәмнәр Раббысы булуын – Аллаһ Тәгалә бары Үзенә генә гыйбадәт кылырга кирәклеген җиткерү, исбатлау һәм дәлилләү өчен китерә. Ягъни, галәмнәр Раббысы – бердәнбер Аллаһ икәнен белгәч, барча гыйбадәтләрне Аңа гына юнәлтү тиешле. Аллаһ Тәгалә әйтте: **“Йә кешеләр! Сезне һәм сездән элек булганнарны бар кылучы Аллаһка гыйбадәт кылыгыз! Аллаһ газабыннан куркып тәкъва булырсыз”.** (“Әл-Бәкъара” сүрәсе, 21-нче аять).

Шулай ук, Аллаһ әйтте: **“Әнә шулай һәрнәрсәне бар итүче Аллаһ сезнең Раббыгыздыр, һәрнәрсәгә патшалык Аның кулындадыр, Аңардан кала башка хак иләһ юк, мәгәр Аллаһ Үзе генәдер. Ничек шулай хактан авыштыгыз?!”** (“Әз-Зүмар” сүрәсе, 6-нчы аять).

Шулай ук, Аллаһ әйтте: **“Алар ошбу Кәгъбәнең Раббысы булган Аллаһка гыйбадәт кылсыннар. Ул – Аллаһ аларны ачлыктан коткарып тукландырды һәм аларны һәртөрле куркынычлардан имин кылды”.** (“Көрайш” сүрәсе, 2-3 нче аятьләр).

Аллаһ Тәгалә Үзенең бердәнбер бар кылучы һәм ризыкландыручы икәнен искәртә, һәм бу мәсьәләдә шикләнүче юк, Аллаһ моны кешеләргә ихласлы рәвештә бары Аңа гына гыйбадәт кылырга кирәклегенә дәлил өчен китерә.

Аллаһ Тәгалә әйтте: **“Әйт: “Аллаһка барча мактау һәм Аның сайлап алган колларына Аллаһның сәламедер. Аллаһ Тәгалә хәерлерәкме яки Аңарга тиңдәш ителгән затлармы? Җир вә күкләрне Кем бар кылды һәм Кем сезгә күктән су иңдерде? Шул су белән чәчәккә күмелгән күп җимеш бакчаларын үстерде, ул бакчаларның агачларын үстеререргә көчегез җитмидер, Аллаһтан башка хак иләһ бармы? Бәлки алар хак юлдан авыша торган кавемдер. Кем җирне селкенми торган итеп бар кылды, җир өстендә күп елгалар агызды һәм җиргә таулар урнаштырды, ике төрле су арасына киртә куйды, бер-берсенә аралашмаслар. Аллаһтан башка хак иләһ бармы? Бәлки аларның күбесе белмиләр. Мохтаҗ кеше дога кылса, аның догасын Кем кабул итә һәм кешеләрдән зарарны Кем җибәрә,**

**һәм сезне җиргә Кем хуҗа кыла? Аллаһтан башка хак иләһ бармы? Бик аз вәгазьләнәсез. Төн караңгылыгында Кем сезне корыда һәм диңгездә йолдызлар белән адаштырмыйча йөртә вә яңгыр алдыннан рәхмәт җилен Кем җибәрә? Аллаһтан башка хак иләһ бармы? Аларның Аллаһка тиңдәш кылган затларыннан Аллаһ пакъ һәм бөектер”.** (“Ән-Нәмел” сүрәсе, 59-63 нче аятьләр).

Алдан китерелгән аятьләрдән шуны күрәбез, мөшрикләр – Аллаһның җирләрне һәм күкләрне бердәнбер бар кылучы, бердәнбер яхшылык яки зарар җибәрүче булуын таный иделәр, әмма аларга бу ышанулары файда китермәде, шуңа күрә Аллаһ Тәгалә аларны инкяр итә, чөнки Аллаһ белән беррәттән башка затларны иләһ итеп, аларга гыйбадәт кыла иделәр. Һәм бу – шәригатькә һәм акылга каршы килә, чөнки бердәнбер бар кылучы, бердәнбер ризыкландыручы, терелтүче һәм вафат кылучы – Аңа гына тиешледер барча гыйбадәт төрләрен юнәлтү!

Шуңа Аллаһ “**Аллаһтан башка хак иләһ бармы?”** дип аларны инкяр итә, әмма “Аллаһтан башка бар кылучы бармы?” дип әйтми, чөнки алар моңа каршы килми иделәр.

Шулай ук, Аллаһ Тәгалә тәүхиднең бу төрендә – Үзенең бердәнбер галәмнәр Раббысы булуында – ширек кылуны инкяр итә: әгәр дә Аллаһ белән беррәттән ниндидер бар кылучы булса, җир һәм күкләр бозылып, яраксызга әйләнер иде. Бу, шулай ук, акыл аша ачыктан-ачык аңлашыла торган мәсьәлә, Аллаһ Тәгалә әйтте: **“Аллаһның баласы һич булмады һәм Аллаһ янында тагын бер иләһ тә булмады, әгәр тагын бер иләһ булса, һәрберсе үзе бар кылганы белән аерылып китер иде вә берсе икенчесеннән өстен булырга тырышыр иде. Аллаһ мөшрикләр сурәтләгән тиешсез сыйфаттан пакътыр”.** (“Әл-Мөэминүн” сүрәсе, 91-нче аять).

Шулай ук: **“Әгәр Аллаһтан кала тагын башка иләһләр булса, әлбәттә, җир вә күк бозылыр иделәр”.** (“Әл-Әнбия” сүрәсе, 22-нче аять). [14]

---

[14] Әлеге аятьләр турында фикерләп карасак, шуны аңларбыз – әгәр дә барча галәмнәрнең ике яки берничә бар кылучысы һәм идарәчесе булса, җир һәм күкләр яраксызланып, тәртипсез хәлгә килерләр иде. Мисал өчен, берсе әйтер иде – “бүген мин бу җирлектә яңгыр яуганын телим”, икенчесе – “юк, монда бүген кояшлы, җылы булсын” дип, һәм, әлбәттә, ахыр чиктә бер-берсе белән килешә алмагач, аятьләрдә әйтелгәнчә, һәрберсе үзенең бар кылганы белән аерылып китер иде яки көчләрәге башкасыннан өстен булып чыгар иде. Әмма, тирәлектә урнаштырылган тәртип, төгәл табигый законнарга буйсынган процесслар әлеге галәмнәрнең бердәнбер бар кылучысы һәм идарәчесе булуына акыл дәлиле булып тора. [“Тәфсир әс-Сәгди”, 532, 570 карарга була. “Мүнтәдә ас-Сәкъафә” нәшрияты].

## Аллаһның исем-сыйфатларына карата дөрес инану.

Аллаһ Тәгалә Үзенә карата яки Аның рәсүле ﷺ Аллаһка карата Аллаһның күркәм исемнәреннән һәм бөек сыйфатларыннан нәрсәне расладылар, Сөннәт һәм Җәмәгать әһелләре дә шуны раслыйлар, ягъни Көръәнне һәм дөреслеге исбатланган хәдисләрне узмыйлар. Бу исем-сыйфатларның атамаларын кабул итәләр, Көръән иңдерелгән гарәп телендәге мәгънәләрен аңлыйлар, әмма аларның кыяфәт-рәвешләрен Аллаһ Тәгаләгә тапшыралар. Чөнки бу исем-сыйфатлар белән бары Аллаһ кына сыйфатланган һәм кешеләргә Ул аларның кыяфәт-рәвешләрен җиткермәгән.

Шуңа алар, бу җитди һәм мөһим бүлектә, шәригатьтә куелган нигезләргә таяналар. Кем шуларга таянды, шул төрле тайпылышлардан имин булыр:

<u>беренчесе</u>, Аллаһ Тәгалә Үзенә яки Аның рәсүле ﷺ Аллаһка карата нәрсәне расладылар – шуны, арттырмыйча һәм киметмичә, раслау тиешле, чөнки Аллаһ турында Аның Үзеннән дә яхшырак белүче юк, Аллаһ Тәгалә әйткәнчә: **“Син аларга әйт: “Сез белүчерәкме, әллә Аллаһмы?”** (“Әл-Бәкъара” сүрәсе, 140-нче аять). Ә инде Үзеннән соң, Аллаһ турында, әлбәттә, Аның рәсүле ﷺ белүчерәк, Аллаһ әйтте: **“Һәм ул [Мөхәммәд] үз белдеге белән сөйләмәс. Аның Ислам хакында сөйләгән сүзе фәкать Аллаһтан иңдерелгән вәхийдер”.** (“Ән-Нәҗем” сүрәсе, 3-4 нче аятьләр).

<u>икенчесе</u>, Аллаһ Тәгаләнең сыйфатларын Аның мәхлукатларының сыйфатларына охшатудан пакълау, моннан ерак булу. Аллаһ Тәгалә әйтте: **“Аллаһка охшаган һичнәрсә юктыр, вә Ул – Ишетүче, Күрүче”.** (“Әш-Шүра” сүрәсе, 11-нче аять). Шулай ук, әйтте: **“Вә һичкем Аңа тиң булмады”.** (“Әл-Ихлас” сүрәсе, 4-нче аять).

<u>өченчесе</u>, Аллаһның сыйфатларының кыяфәт-рәвешләрен төшенүгә тырышудан ерак булу. Аллаһ Тәгалә әйтте: **“Әмма кешеләр, Аллаһны белемнәре белән чолгап ала алмаслар”.** (“Таһә” сүрәсе, 110-нчы аять). Шулай ук, әйтте: **“Әллә син беләсеңме Аллаһ белән бер исемнәрдә булган берәр затның барлыгын?”.** (“Мәрьям” сүрәсе, 65-нче аять).

Аллаһның сыйфатларыннан булып Аның Гәрешкә күтәрелүе (“әл-истивә”) тора, Аллаһ Тәгалә әйткәнчә: **“Ул – Аллаһ Гәрешкә күтәрелде”.** (“Таһә” сүрәсе, 5-нче аять). Мондый мәгънәдәге аятьләр Көръәндә берничә урында килә, шулардан аңлыйбыз: Аллаһ Тәгалә хакыйкый рәвештә Гәрешкә күтәрелде, ягъни **“күтәрелде”** (“истәвә гәлә”) дигән сүзнең мәгънәсе яшерен түгел, аңлашыла, әмма ни рәвешле булуы безгә билгесез.

Ягъни, гарәп телендә бу гыйбарә “югары булу, күтәрелү” дигән мәгънәгә ия, Сөннәт һәм Җәмәгать әһелләре моны бертавыштан расладылар. Әмма, Аллаһның Гәрешкә күтәрелү рәвешен бары Аллаһ Үзе генә белә. [15]

Шулай ук, Аллаһның “ишетү” һәм “күрү” сыйфатлары бар, Аллаһ Тәгалә әйткәнчә: **“Әлбәттә, Аллаһ – Ишетүче, Күрүче”.** (“Ән-Нисә” сүрәсе, 58-нче аять). Әлеге һәм моңа охшаш башка аятьләрдән шуны аңлыйбыз: Аллаһның “ишетү” дигән сыйфаты бар, гарәп телендә бу сүз “тавышларны үзләштерү” мәгънәсендә килә. Димәк, Аллаһ

---

15 Димәк, Аллаһның сыйфатларын ишеткәндә нәрсәдер күзаллау бер дә ярамый. Чөнки, алдан әйткәнчә, Аллаһ Тәгалә Үзенең мәхлукатларына охшаш түгел.

Тәгаләнең тавышларны ишетү сыйфаты бар, әмма Аның бу сыйфаты Үзенең мәхлукатларының сыйфатларына һич тә охшамаган. Шуңа күрә, Аллаһның ишетү рәвешен без белмибез, моны Аның Үзенә тапшырабыз һәм “Аллаһ ничек, ни рәвешле ишетә” дип сорау бирмибез, ягъни бу мәсьәләдә төпченмибез. Аллаһ Тәгалә безгә моны ачмаган, бәлки, бу гыйлемне Үзендә калдырган. [16]

Нәкъ шулай ук, “күрү” сыйфаты: мәгънәсе билгеле – “күренә торганны үзләштерү”. Әбү Мүсә әл-Әшгәри رضي الله عنه исемле сахабәдән килә, пәйгамбәребез ﷺ әйткән: ***“Чынлыкта, Аллаһ йокламый, һәм Аңа йоклау тиешле дә түгел; Ул ризыкны киметә һәм арттыра (***яки: ***Аңа китерелгән гамәлләрнең авырлыгын киметә һәм арттыра); Аңа, көндезге гамәлләр алдыннан, төнге гамәлләр күтәрелә, төнге гамәлләр алдыннан, көндезгеләре күтәрелә; Аның пәрдәсе – нур, әгәр дә Ул шул пәрдәне алса, Йөзенең балкуы – карашы җиткән барча мәхлукатны яндырыр иде”.*** (Мөслим, 179).

Димәк, Аллаһ Тәгаләнең, хакыйкый, барчалыкны күрү сыйфаты бар. Әмма инде, бу сыйфатның рәвешен без, шулай ук, белмибез, бары Аллаһ безгә җиткергәнне генә беләбез: **“Аллаһка охшаган һичнәрсә юктыр, вә Ул – Ишетүче, Күрүче”.** (“Әш-Шүра” сүрәсе, 11-нче аять).

Шулай итеп, Сөннәт әһелләренең Аллаһның исем-сыйфатларына карата инануларына кайбер мисаллар китердек.

---

[16] Шуны аңлау мөһим: акылны һәрнәрсәдән өстен куеп, акыл белән бар нәрсәне дә аңлап була дип, яки “минем акылым нәрсәне аңлый – кабул итәм, нәрсәне аңламый – шуны юк” дип фикер йөртү хата булып тора. Чөнки, без – Аллаһ бар иткән затлар, Аның коллары, һәм безнең ишетү, күрү, ис тою сәләтләре чикләнгән кебек, акылыбыз да Аллаһ тарафыннан чикләнгән. Шуңа күрә, акыл аша гына Аллаһның сыйфатларын төшенергә мөмкин түгел. Хәтта, без үзебездә булган “җанны” да нәрсә, ни рәвешле икәнен һәм нинди матдәдән ясалганын белмибез. Аллаһ Тәгалә әйткәнчә: **“Синнән рух турында сорашалар, син аларга әйт: “Рух – Аллаһның әмереннәндер, һәм сезгә белемнән бик аз өлеш бирелде”.** (“Әл-Исра” сүрәсе, 85-нче аять).

**<u>Аллаһның бердәнбер гыйбадәткә лаеклы Зат булуына карата дөрес инану.</u>**

Сөннәт һәм Җәмәгать әһелләре Аллаһ Тәгалә бердәнбер гыйбадәткә лаеклы Зат булуын таныйлар, үзләренең гамәл-гыйбадәтләрен Аллаһ белән беррәттән башкаларга багышламыйлар, Аллаһ әмер иткән барча гамәлләре белән бары бер Аңа гына юнәләләр.

Намаз-сәҗдәләрен, Кәгъбәтуллаһ тирәли тәвафларын Аллаһка гына кылалар, корбаннарын, нәзерләрен Аңа гына багышлыйлар, Аллаһ исеме белән генә ант итәләр, бары бер Аңа гына тәвәккәл кылалар, Аллаһка гына дога белән ялваралар.

Аллаһ Тәгалә әйтте: **“Аллаһның Үзенә генә гыйбадәт кылыгыз, Аңа һичкемне, һичнәрсәне тиңдәш кылмагыз”.** (“Ән-Нисә” сүрәсе, 36-нчы аять).

Шулай ук, әйтте: **“Аллаһ хөкем итте вә әмер бирде, фәкать Аңа гына гыйбадәт кылырга”.** (“Әл-Исра” сүрәсе, 23-нче аять).

Шулай ук: **“Аларга бердәнбер иләһкә – Аллаһка гына гыйбадәт кылырга боерылган иде”.** (“Әт-Тәүбә” сүрәсе, 31-нче аять).

Шулай ук: **“Ә бит аларга Аллаһка ихлас рәвештә хәниф булып гыйбадәт кылырга, намаз үтәргә һәм зәкәт бирергә генә әмер кылынган иде”.** (“Әль-Бәййинә” сүрәсе, 5-нче аять).

Аллаһ Тәгалә, шулай ук, әйтте: **“Кеше һәм җенне бары Миңа гыйбадәт кылсыннар өчен генә халык кылдым”.** (“Әз-Зәрият” сүрәсе, 56-нчы аять). Монда **“гыйбадәт кылсыннар өчен генә”** дигән гыйбарә “гыйбадәтләрендә Мине берләсеннәр” дигән мәгънәдә килә.

Ихласлы булып, бер Аллаһка гына гыйбадәт кылуның капма-каршысы булып ширек тора, бу Аллаһ тарафыннан тыелган гамәлләрнең иң зурысы һәм начары, Аллаһ Тәгалә безләрне моннан сакласа иде! Аллаһ Тәгалә әйтте: **“Аллаһ үзенә ширек кылуны гафу итмәс, башка гөнаһларны кемгә тели, шуңа гафу итәр. Бер кеше Аллаһка кемнедер, нәрсәнедер ширек кылса, дөреслектә, ул Аллаһка олы ялганны уйлап чыгаручыдыр”.** (“Ән-Нисә” сүрәсе, 48-нче аять).

Башка аятьтә әйтте: **“Аллаһ үзенә ширек кылуны гафу итмәс, башка гөнаһларны кемгә тели, шуңа гафу итәр. Бер кеше Аллаһка кемнедер, нәрсәнедер ширек кылса, дөреслектә, ул ерак адашу белән адашучыдыр”.** (“Ән-Нисә” сүрәсе, 116-нче аять).

Шулай ук, әйтте: **“Батыл диннән Аллаһ диненә күчкәнегез хәлдә Аллаһка мәхлукны тиңдәш итмичә, хаҗ гамәлләрен үтәгез, берәү Аллаһка мәхлукны тиң итсә, ул күктән егылып төшкән хәлдә булыр, вә аны кошлар тотып алырлар яисә җил аны ерак җиргә илтеп ташлар”.** (“Әл-Хәҗ” сүрәсе, 31-нче аять).

Шулай ук: **“Локман улын вәгазьләп әйтте: “Йә улым, Аллаһка ширек кылма, чынлыкта, ширек – бик олы золымдыр”.** (“Локман” сүрәсе, 13-нче аять).

Аллаһ Тәгалә ширекне – гамәлләрне юкка чыгаручы, кешене Ислам диненнән читкә куючы гамәл булуын аңлатты, һәм әйтте: **“Әгәр дә алар Аллаһка тиңдәшлек китереп**

**ширек кылсалар, әлбәттә, кылган изге гамәлләре югалыр иде”.** (“Әл-Әнгәм” сүрәсе, 88-нче аять).

Шулай ук: **“Сиңа һәм синнән әүвәлге пәйгамбәрләргә вәхий ителде, әгәр Аллаһка бернәрсәне ширек кылсаң, әлбәттә, гамәлләрең батылга әйләнер вә үзең дә һәлак булучылардан булыр идең”.** (“Әз-Зүмар” сүрәсе, 65-нче аять).

Имам Мөслимнең “Сахих” хәдисләр җыентыгында Җәбир ибн Гәбдуллаһ رضي الله عنه исемле сахабәдән килә, пәйгамбәребез ﷺ: ***“Кем Аллаһны Аңа беркемне дә һәм бернәрсәне дә ширек кылмыйча очрата, шул Җәннәткә керәчәк, ә кем Аны кемне яки нәрсәне булса да ширек китереп очрата, шул Утка керәчәк”*** – дип әйткән.

Имам әл-Бохариның “Сахих” хәдисләр җыентыгында ибн Мәсгүд رضي الله عنه исемле сахабәдән килә, пәйгамбәребез ﷺ әйткән: ***“Кем Аллаһка кемнедер яки нәрсәнедер тиңдәш кылып, шуңа гыйбадәт кылган хәлдә вафат була, шул Утка керәчәк”*** – дигән.

Димәк, әгәр дә берәр кем гыйбадәтнең ниндидер төрен Аллаһ Тәгаләдән башкаларга юнәлтә икән, бу кеше имансыз мөшрик була. Мисал өчен, дога кылу – Аллаһ Тәгалә яраткан һәм әмер иткән гыйбадәтнең бер төре, кем дога белән бер Аллаһка гына ялвара – бу Аллаһны берләүче мөэмин-мөселман, ә кем дога белән башкаларга ялвара – шул ширек гамәле кылучы булыр. [17]

Аллаһ Тәгалә әйтте: **“Сиңа файда да, зарар да китерә алмаган башка [иләһләргә] гыйбадәт кылма. Әгәр син бу эшләрне эшләсәң, әлбәттә, залимнәрдән булырсың”.** (“Йуныс” сүрәсе, 106-нчы аять).

Шулай ук, әйтте: **“Берәү Аллаһ белән бергә башка иләһкә гыйбадәт кылса, аның бу эшенә һич дәлиле юктыр, аның хөкем ителеше фәкать Раббысы каршындадыр. Имансызлар уңышка ирешә алмаслар!”** (“Әл-Мөэминүн” сүрәсе, 117-нче аять).

Шулай ук, әйтте: **“Вә мәчетләр Аллаһка гыйбадәт кылу өчендер, Аллаһтан башка һичкемгә дә һәм һичнәрсәгә дә гыйбадәт кылмагыз! Аллаһ колы Мөхәммәд аулакта намазга торып, кычкырып Коръән укыганда, Коръән тыңлау өчен аның янына килеп җеннәр бер-берсенең өстенә өелә яздылар. Әйт: “Мин фәкать Аллаһка гына гыйбадәт кыламын, Аңарга һичкемне шәрик-тиңдәш кылмыймын””.** (“Әл-Җин” сүрәсе, 18-20 нче аятьләр).

---

17 Димәк, ниндидер гамәлнең гыйбадәт гамәл булуы расланган икән, бу гамәлне Аллаһтан башкаларга юнәлтү ширек булып, кешене имансызлар рәтенә чыгарыр, Аллаһ Тәгалә әйткәнчә: **“Берәү Аллаһ белән бергә башка иләһкә гыйбадәт кылса, аның бу эшенә һич дәлиле юктыр, аның хөкем ителеше фәкать Раббысы каршындадыр. Имансызлар уңышка ирешә алмаслар!”** (“Әл-Мөэминүн” сүрәсе, 117-нче аять). Әмма бу гомуми хөкем, ә инде үзен мөселман дип атап, “Лә иләһә иллә-Ллаһ, Мүхәммәдүн расүлү-Ллаһ” кәлимәсен әйтеп тә, ләкин, шуның белән бергә, берәр нинди ширек яки көферлек гамәлен кылучы кешегә карата мондый хөкемне куллануга сак каларга кирәк. Чөнки мөселман кешесен Ислам диненнән чыгаруның галимнәр тарафыннан расланган шартлары бар, бу – галимнәрнең һәм кадыйларның өстенлеге, һәм фикыһ китапларында тирәнтен үтелә.

Аллаһ Тәгалә, шулай ук, әйтте: **“Бары Аллаһка гына хак өндәү тиешле. Ә Аннан кала башкаларга табына торган затлар һичбер сорауларына җавап бирә алмыйлар, аларның мисалы: авызыма су керсен дип, суга таба кулын сузып торган кеше кебек, күпме генә суга карап кул сузып торсалар да, суның авызларына килеп керәчәге юк. Имансызларның догалары адашудан кала берни түгел”.** (“Әр-Рагыд” сүрәсе, 14-нче аять).

Шулай ук, әйтте: **“Әмма мөшрикләрнең Аллаһтан башка гыйбадәт кыла торган затлары һичнәрсәне бар кыла алмыйлар, алар үзләре бар кылынганнар. Ул затлар һич терелми торган үлекләр, һәм кайчан кубарылачакларын да белмиләр”.** (“Ән-Нәхел” сүрәсе, 20-21 нче аятьләр).

Шулай ук: **“Аллаһтан башка иләһкә гыйбадәт кылма, югыйсә газапка дучар булырсың”.** (“Әш-Шүгәра” сүрәсе, 213-нче аять).

Шулай ук, әйтте: **“Аллаһ кичне көндезгә кертеп көнне озын кылыр, вә көндезне көнгә кертеп төнне озын кылыр, вә кешеләрне кояш вә айдан файдаландырды, һәрберсе билгеләнгән көнгә чаклы һава бушлыгында йөзеп йөрерләр, шул гаҗәеп эшләрне кылучы Раббыгыз Аллаһтыр, барча милек Аңа гынадыр. Аллаһтан башка гыйбадәт кыла торган затларыгыз хөрмә җимешенең элпәсенә дә ия түгелләр. Алардан ярдәм сорап дога кылсагыз – сезнең догагызны ишетмиләр, ишеткән булсалар да, җавап бирә алмыйлар. Вә кыямәт көнендә алар сезнең ширек гамәлегезне кире кагырлар. Һәрнәрсәдән хәбәрдар булучы Аллаһтан кала һичкем дә сиңа моны белгертә алмас”.** (“Фәтыр” сүрәсе, 13-14 нче аятьләр).

Аллаһ Тәгалә, шулай ук, әйтте: **“Әгәр син алардан сорасаң – җир вә күкләрне кем бар кылды дип, әлбәттә – Аллаһ, диярләр. Әйт: “Әгәр Аллаһ миңа бер зарар ирештерергә теләсә, сезнең Аллаһтан башка гыйбадәт кылган затларыгыз шул зарарны миннән җибәрә алырлармы, яки Аллаһ миңа рәхмәт ирештерергә теләсә, ул рәхмәтне миңа җибәрмичә тотып калырга аларның көчләре җитәрме?! Әйт: “Миңа һәр эштә ярдәм бирергә вә мине сакларга Аллаһ җитәдер, хак тәвәккәл итүчеләр, әлбәттә, Аллаһка гына тәвәккәл кылырлар”.** (“Әз-Зүмар” сүрәсе, 38-нче аять).

Аллаһ Тәгалә әйтте: **“Аларга әйт: “Беләсезме Аллаһтан башка гыйбадәт кылган затларыгызны, миңа күрсәтегез – җирдә нәрсә бар кылдылар, яки Аллаһка тиң булып, Аның белән бергә күкләрне төзеделәрме? Инде Коръәннән әүвәл иңгән бер китапны китерегез, яки гыйлемнән дәлил эзләрен күрсәтегез, әгәр дөрес сөйләүчеләрдән булсагыз”. Аллаһтан башка затка гыйбадәт кылучы кешедән дә адашучырак кеше бармы, дога-сорауларына Кыямәт көненә хәтле җавап бирмәсләр, һәм аларның дога кылганнарын бөтенләй дә белмәсләр. Кешеләр каберләрдән кубарылганда бу затлар аларга гыйбадәт кылучыларга дошман булырлар, вә гыйбадәтләрен инкяр итерләр”.** (“Әл-Әхкъаф” сүрәсе, 4-6 нчы аятьләр).

“Әс-Сүнән” китапларында килә – Ән-Нүгмән ибн Бәшир رضي الله عنه исемле сахабә әйткән: *пәйгамбәребез ﷺ әйтте:* ***“Дога – ул гыйбадәт”*** – дигән.

Тәүхиднең шушы төрендә, ягъни Аллаһның бердәнбер гыйбадәткә лаеклы Зат булуын тануда, пәйгамбәр-рәсүлләр белән аларның кавемнәре арасында низаг булды.

Аллаһ Тәгалә рәсүлләрне дә әлеге тәүхидне төшендерү һәм халыкларны шуңа чакыру өчен җибәрде, Изге Китапларын да шуны беркетү, аңлату һәм дәлилләү өчен иңдерде. Аллаһ Тәгалә әйткәнчә: **“Өммәтләрнең һәрберсенә рәсүлләр җибәрдек, фәкать Аллаһка гына гыйбадәт кылыгыз һәм Аллаһтан башкаларга гыйбадәт кылудан сакланыгыз”.** (“Ән-Нәхел” сүрәсе, 36-нчы аять).

Аллаһ Тәгалә, шулай ук, әйтте: **“Синнән элек кайсы гына рәсүлне җибәрсәк тә – һәрберсенә вәхий иңдердек: “Дөреслектә, Миннән башка гыйбадәт кылырга яраклы һичбер иләһ юк, мәгәр Мин үзем генә, Миңа гына гыйбадәт кылыгыз!”.** (“Әл-Әнбия” сүрәсе, 25-нче аять).

Шулай ук, әйтте: **“Аллаһ Тәгалә колларыннан Үзе теләгән бәндәләренә Үзенең әмере белән фәрештәләр аша вәхий иңдерә: башкаларны кисәтегез – Миннән башка хак иләһ юк, Миннән куркыгыз!”** (“Ән-Нәхел” сүрәсе, 2-нче аять).

Рәсүлләр үзләренең кавемнәрен Аллаһка чакыруларын шуның белән ачып җибәрделәр, һәрберсе әйтә торган булган: **“Йә каумем! Фәкать Аллаһка гына гыйбадәт кылыгыз, Аннан кала сезнең хак иләһегез юк”.** (“Әл-Әграф” сүрәсе, 59,65,73,85-нче аятьләр). Бу сүзләрне Нух, Һүд, Салих, Шүгәйб һ.б. пәйгамбәрләр әйттеләр, аларның барчасына да Аллаһның мактавы һәм сәламе булсын!

Аллаһ Тәгалә әйтте: **“Вә Ибраһим кавеменә: “Аллаһка гына гыйбадәт кылыгыз, вә Аннан куркыгыз, бу әйткәннәрне кылсагыз үзегез өчен хәерледер, әгәр белсәгез”, – диде. “Аллаһтан башка сынымнарга гыйбадәт кыласыз, вә ялган уйлап чыгарасыз, бит Аллаһтан башка гыйбадәт кыла торган сынымнарыгыз сезгә ризык бирә алмыйлар, ризыкны Аллаһтан сорагыз вә Аңа гына гыйбадәт кылыгыз һәм Аңа шөкер итегез, чөнки хөкем ителергә Аллаһка кайтасыз” – диде”.** (“Әл-Гәнкәбүт” сүрәсе, 16-17 нче аятьләр).

Шулай ук, Аллаһ Тәгалә Үзенең пәйгамбәре Йосыф عليه السلام турында хәбәр бирде: **“Йосыф әлеге төш күрүче ике егетне башта вәгазьләргә теләде һәм аларга әйтте: “Йә зиндандагы ике иптәшем! Ясалма күп иләһләргә гыйбадәт кылу хәерлеме? Яки һич тиңдәше булмаган бөтен мәхлукның хуҗасы вә кодрәт иясе бер генә Аллаһка гыйбадәт кылу хәерлеме? Сез, бары, үзегез вә аталарыгыз иләһ дип исем биргән һичнәрсәгә ярамый вә файда бирми торган затларга гыйбадәт кыласыз, аларга гыйбадәт кылуның дөреслеге өчен Аллаһ һич дәлил иңдергәне юк, хөкем чыгару фәкать Аллаһка гынадыр, Ул – Аллаһ үзеннән башкага гыйбадәт кылмаска әмер кылды, бу ислам дине – хак, туры дин, ләкин күп кешеләр белмиләр”.** (“Йосыф” сүрәсе, 39-40 нче аятьләр).

Мөшрикләрнең үзләренең ширек гамәлләренә сәламәт акыл ягыннан да, пәйгамбәрләр алып килгән гыйлем ягыннан да таянычлары юк. Аллаһ Тәгалә әйтте: **“Синнән элек җибәргән расүлләребездән сора: “Әллә Без Рәхмәт иясе Аллаһтан башка гыйбадәт кылырга яраклы иләһләр булдырдыкмы?”** (“Әз-Зүхруф” сүрәсе, 45-нче аять). Ягъни, бер

генә пәйгамбәр-рәсүл дә Аллаһ беләң беррәттән төрле иләһләргә гыйбадәт кылырга чакырмаган, киресенчә, һәрберсе дә бары бер Аллаһка гына гыйбадәт кылырга өндәгән.

Шулай ук, Аллаһ Тәгалә ширек гамәлен инкяр итү өчен акыл дәлилен дә китерә: **“Аларга әйт: “Беләсезме Аллаһтан башка гыйбадәт кылган затларыгызны, миңа күрсәтегез – җирдә нәрсә бар кылдылар, яки Аллаһка тиң булып, Аның белән бергә күкләрне төзеделәрме? Инде Коръәннән әүвәл иңгән бер китапны китерегез, яки гыйлемнән дәлил эзләрен күрсәтегез, әгәр дөрес сөйләүчеләрдән булсагыз”.** (“Әл-Әхкъаф” сүрәсе, 4-нче аять). Бу аятьтә Аллаһтан кала башка затларга гыйбадәт кылу батыл гамәл булуга катгый дәлил китерелә – чөнки бу затлар бернәрсәне дә бар итмәделәр, Аллаһның бар кылуында Аңа ярдәмче дә булмадылар, бары Аллаһ Үзе генә бар нәрсәне бар кылды, димәк, нигә дип кешеләр башка затларга гыйбадәт кылалар? Ягъни, ширек гамәлләренә юнәлергә мөшрикләрнең ни акыл ягыннан, ни пәйгамбәр-рәсүлләрдән яки иңдерелгән Изге Китаплардан бернинди дәлилләре дә юклыгы ачык билгеле, шуңа күрә, алар Җәһәннәмдә мәңге калучылар, вә ул ни яман урындыр.

Тәүхиднең бу төре һәрбер кешегә иң беренчел һәм иң мөһим мәсьәлә. Аллаһ Тәгалә беркемнән дә башка динне кабул итми.

**Иманның алты нигезенә карата дөрес инану.**

Сөннәт һәм Җәмәгать әһелләре: Аллаһка, Аның фәрештәләренә, Изге Китапларына, рәсүлләренә, үлемнән соң терелүгә һәм тәкъдиргә иман китергәннәр.

***Аллаһка иман:***

Моңа Аллаһның бердәнбер галәмнәр Раббысы һәм бердәнбер гыйбадәткә лаеклы Зат булуын, Аның исем-сыйфатларын раслау кирә. Моны алдан аңлатып уздык.

***Фәрештәләргә иман:***

Моңа фәрештәләрнең барлыгын тану, исемнәре билгеле булганнарын шул исемнәре белән атау һәм аларга йөкләнелгән гамәлләрне раслау кирә. Аллаһ Тәгалә әйтте: **“Аллаһ илчесе Мөхәммәд Раббысыннан иңдерелгәнгә иман китерде һәм мөэминнәр дә иман китерделәр, алар һәммәсе Аллаһка, Аның фәрештәләренә, Китапларына, рәсүлләренә иман китерделәр”.** (“Әл-Бәкъара” сүрәсе, 285-нче аять).

Аллаһ Тәгалә, шулай ук, әйтте: **“Изгелек ул кояш чыга торган якка һәм кояш бата торган якка юнәлеп гыйбадәт кылуларыгыз гына түгел. Ләкин изгелек – берәү Аллаһка, ахирәт көненә, фәрештәләргә, Китапларга һәм пәйгамбәрләргә иман китерсә”.** (“Әл-Бәкъара” сүрәсе, 177-нче аять).

Имам Мөслимнең “Сахих” хәдисләр җыентыгында Гүмәр ибн Әл-Хаттабтан رضي الله عنه озын хәдис килә, анда Җәбраил عليه السلام пәйгамбәребездән ﷺ иман турында сорый, һәм пәйгамбәребез ﷺ: ***“Иман ул – синең Аллаһка, Аның фәрештәләренә, Изге Китапларына, рәсүлләренә, ахирәт көненә, тәкъдирнең яхшысына да, яманы да ышануың”*** – дигән.

Аллаһ Тәгалә Үзенең Китабында фәрештәләрне сыйфатлый, мәсәлән, әйтә: **“Җирдә вә күкләрдә булган затлар Аллаһ мәхлукларыдыр, вә Аның хозурында булган фәрештәләр Аллаһка гыйбадәт кылудан тәкәбберләнмәсләр һәм ялыкмаслар. Төнне вә көндезен Аллаһны мактап тәсбих әйтерләр, һич тә арымаслар”.** (“Әл-Әнбия” сүрәсе, 19-20 нче аятьләр).

Аллаһ Тәгалә, шулай ук, әйтте: **“Бәлки фәрештәләр – Аллаһның хөрмәтле колларыдыр. Алар сүзләре белән Аллаһны һич тә узмаслар вә Аллаһның әмере буенча эш кылырлар”.** (“Әл-Әнбия” сүрәсе, 26-27 нче аятьләр).

Шулай ук, әйтте: **“Раббың хозурында булган фәрештәләр Аллаһка гыйбадәт кылудан зурланмыйлар вә Аллаһны мактап тәсбихләр әйтәләр һәм Аллаһка сәҗдә кылалар”.** (“Әл-Әграф” сүрәсе, 206-нчы аять).

Фәрештәләр – Аллаһның коллары, Аның бар иткән бөек затлары. Ләкин алар гыйбадәттән һичнәрсәгә дә лаек түгелләр. Аллаһ Тәгалә әйтте: **“Без аларның барчасын кубарырбыз, аннан фәрештәләргә әйтербез: “Ошбу мөшрикләр сезгә гыйбадәт кылдылармы?” Фәрештәләр әйттеләр: “Йә Раббыбыз, Син һәр кимчелектән пакъ, Син генә безнең яклаучыбыз, мөшрикләр түгел, бәлки алар җен-шайтаннарга гыйбадәт кылалар иде, аларның күбрәге шуларга ышана иделәр”.** (“Сәбә” сүрәсе, 40-41 нче аятьләр).

Аллаһ Тәгалә, шулай ук, әйтте: **“Ул пәйгамбәр сезгә фәрештәләрне вә пәйгамбәрләрне иләһ итеп алыгыз димәс. Әллә пәйгамбәр сезне мөселман булганыгыздан соң көферлеккә өндәрме?!”** (“Әли-Гыйран” сүрәсе, 80-нче аять).

Имам Мөслимнең “Сахих” хәдисләр җыентыгында Гаишәдән رضي الله عنها хәдис килә, пәйгамбәребез ﷺ әйткән: ***“Фәрештәләр – нурдан, җеннәр – уттан булган ялкыннан, ә Адәм – сезгә инде сыйфатланып үтелгәннән** (ягъни туфрактан) **бар кылындылар”*** – дигән.

Шулай ук, фәрештәләрнең канатлары булуы да билгеле, кайберләрендә икешәр-икешәр, кайберләрендә өчәр-өчәр, башкаларында дүртәр-дүртәр һәм башка санда канатлары бар. Аллаһ Тәгалә әйтте: **“Барча мактау җир вә күкләрне халык кылучы, фәрештәләрне икешәр, өчәр, дүртәр канатлы итеп бар кылып илче итүче Аллаһка тиешле. Ул Үзенең бар иткәненә нәрсә өстисе килә, шуны арттыра. Аллаһның һәрнәрсәгә көче җитәдер”.** (“Фәтыр” сүрәсе, 1-нче аять).

Имам әл-Бохариның “Сахих” хәдисләр җыентыгында Ибн Мәсгүдтән رضي الله عنه хәдис килә: “*пәйгамбәребез ﷺ Җәбраил фәрештәне күргән, аның алты йөз канаты булган”*. [18]

Шулай ук, фәрештәләр төрле күркәм кыяфәтләргә керә алалар. Мәсәлән, Җәбраил عليه السلام Мәрьям янына матур кыяфәтле ир рәвешендә килде, яки, берничә фәрештә төркеме Ибраһим пәйгамбәргә ﷺ хөрмәтле кунаклар рәвешендә өенә керделәр, яки Лүт пәйгамбәр عليه السلام кавемен газапка тарту өчен Лүт янына, шулай ук, матур кыяфәтле егетләр рәвешендә керделәр, һәм мондый мисаллар бик күп.

Аллаһ Тәгалә фәрештәләрне Аллаһның кызлары дип атаучы мөшрикләрнең сүзләрен инкяр итә: **“Мөшрикләр Аллаһның баласы бар диделәр. Аллаһ һәр кимчелектән пакъ! Бәлки фәрештәләр – Аллаһның хөрмәтле колларыдыр. Алар сүзләре белән Аллаһны һич тә узмаслар вә Аллаһның әмере буенча эш кылырлар. Аллаһ аларның үткәндәге эшләгән эшләрен вә киләчәктә эшләячәк эшләрен белер, ул фәрештәләр шәфәгать итмәсләр, мәгәр Аллаһ риза булган кешегә генә шәфәгать итәрләр, вә алар Аллаһтан куркып түбәнчелек кылучылар”.** (“Әл-Әнбия” сүрәсе, 26-28 нче аятьләр).

Шулай ук, Аллаһ Тәгалә әйтте: **“Син алардан сорап кара: “Әллә Аллаһка – кыз, ә мөшрикләргә – ир балалармы?” Яки Без фәрештәләрне кызлар итеп бар кылганыбызны алар күреп тордыламы? Аларның ялган сүзләреннәндер Аллаһның баласы бар дип әйтүләре, чынлыкта, алар ялган сөйлиләрдер. Сез – Аллаһ ир балаларны калдырып, Үзенә кыз балаларны сайлады дисезме? Сезгә ни булды, ничек хөкем итәсез? Аз гына булса да уйлап-фикерләп карамыйсызмы?**

---

18 Монда әйтеп үтик, Аллаһ Тәгаләнең һәрнәрсәгә көче җитә. Мисал өчен, иттән һәм сөяктән торган кешене ике кул белән тотып эшләүче, ике аякка басып йөрүче итү дә, кошларны канатлы итеп һава бушлыгында очыртып йөртү дә Аллаһка бернинди дә авырлык тудырмый. Шулай ук, фәрештәләрне дә безнең күзебездән яшереп, аларга канатлар биреп, төрле кыяфәттә бар итү дә Аллаһка бернинди авырлык китерми.

**Яки сезнең ачык бер дәлилегез бармы? Китабыгызны китерегез, әгәр дөрес сөйләүчеләрдән булсагыз”.** (“Әс-Саффәт” сүрәсе, 149-157 нче аятьләр).

Шулай ук, Аллаһ Тәгалә фәрештәләр турында әйтте: **“Фәрештәләр әйтте: безнең арабызда һәрберсенә билгеләнгән гыйбадәт урыны бардыр. Вә без гыйбадәттә, әлбәттә, саф-саф булып торабыз. Вә без Аллаһ Тәгаләгә тәсбихләр әйтәбез”.** (“Әс-Саффәт” сүрәсе, 164-166 нчы аятьләр).

Шулар арасыннан – Җәбраил عليه السلام, Аллаһтан пәйгамбәрләргә вәхий алып килү белән йөкләнелгән. Аллаһ Тәгалә әйтте: **“Кем Җәбраил фәрештәгә дошман булса, ә бит ул Коръәнне Аллаһ әмере белән синең күңелеңә иңдерде”.** (“Әл-Бәкъара” сүрәсе, 97-нче аять).

Пәйгамбәребез ﷺ Җәбраил фәрештәне үз кыяфәтендә ике мәртәбә күргән: беренчесе – пәйгамбәрлеге башланган чорында, аның алты йөз канаты булган һәм ул үзенең зурлыгы белән бөтен офыкны каплаган; икенчесе – әл-Исра үәл-Миграҗ төнендә күктә күргән: **“Ул Җәбраилнең төшүен тагын бер мәртәбә күрде. Чиктә булган Лотос агачы янында. Кайта торган Җәннәт шул агач янындадыр”.** (“Ән-Нәҗем” сүрәсе, 13-15 нче аятьләр). Башка вакытларда Җәбраил عليه السلام аның янына ир-ат кыяфәтендә килгән, күп очракта Дихъя әл-Кәлби رضي الله عنه исемле сахабә рәвешендә.

Аллаһ Тәгалә Җәбраил عليه السلام турында әйтте: **“Шиксез, ул Коръән хөрмәтле Җәбраилнең Аллаһтан алып килгән сүзедер. Гәреш иясе Аллаһ хозурында ул олугъ куәт ияседер. Аңа башка фәрештәләр буйсыналар һәм ул ышанычлы, хыянәттән иминдер. Вә сезнең юлдашыгыз Мөхәммәд акылдан язмады. Чынлыкта, Җәбраилне ул күрде ачык офыкта”.** (“Әт-Тәкүир” сүрәсе, 19-23 нче аятьләр).

Шулай ук, фәрештәләр арасыннан – Микәил عليه السلام, яңгырлар өчен җаваплы итеп куелган, Аллаһ Тәгалә әмер иткән җиргә болытларны йөртә.

Имам Әхмәднең хәдисләр җыентыгында Әнәс ибн Мәликтән رضي الله عنه хәдис килә: *“Пәйгамбәребез ﷺ Җәбраилдән сораган:* ***“Нишләп мин бер дә Микәилнең көлгәнен күргәнем юк? Җәбраил: “Аның Ут барлыкка китерелгән вакыттан бирле көлгәне юк”*** *– дип әйткән”.*

Аллаһ Тәгалә Микәил عليه السلام турында әйтте: **“Берәр кем Аллаһка һәм Аның фәрештәләренә, пәйгамбәрләренә, Җәбраилгә һәм Микәилгә дошман булса – чынлыкта, Аллаһ имансызларга дошмандыр”.** (“Әл-Бәкъара” сүрәсе, 98-нче аять).

Фәрештәләр арасыннан – Исрафил عليه السلام, Кыямәт көне җиткәнне белдертеп, Аллаһның әмере белән, быргыга өрүче итеп куелган. Беренче өрүендә барча тереклек аңын җуяр, икенчесендә барчасы да кубарылып чыгырлар һәм Раббылары каршына килерләр.

Бу өч фәрештәне пәйгамбәребез ﷺ үзенең төнге намазларын башлап җибәргәндә искә ала торган булган: ***“Йә Аллаһ – Җәбраилнең, Микәилнең һәм Исрафилның Раббысы, күкләрне һәм җирне төзүче, яшерен һәм ачыкны белүче – Син фикер каршылыкларында колларыңны хөкем итәчәксең, бу каршылыкларда Үзеңнең***

***әмереӊ белән мине хактан алып бар, Син бит кемне телисеӊ, шуны туры юлдан алып барасыӊ”.*** (Хәдисне имам Мөслим китерә).

Шулай ук, фәрештәләрдән – Үлем фәрештәсе, җаннарны алу белән йөкләнелгән. Аллаһ Тәгалә әйтте: **“Әйт: “Сезне вафат кылырга вәкил ителгән Үлем фәрештәсе җаныгызны алыр, соңрак каберләрегездән кубарылып Раббыгызга кайтырсыз”.** (“Әс-Сәҗдә” сүрәсе, 11-нче аять). [19]

Шулай ук, фәрештәләрдән – Аллаһ Тәгалә рөхсәте белән кешеләрне сакларга дип куелганнары бар: **“Сездән берәү сүзен кычкырып сөйләсен яки яшерен сөйләсен, вә берәү кич караңгысында яшереп эш кылсын, кирәк – көндезен күрсәтеп эш кылсын – Аллаһ һәммәсен бертигез белә. Вә һәр кешенеӊ алдыннан вә артыннан фәрештәләр бар, Аллаһ әмере белән кешеләрне саклар. Чынлыкта, Аллаһ бер кавемгә биргән нигъмәтен үзгәртмәс, хәтта ул кавем үз хәлен үзгәрткәнгә чаклы. Вә әгәр бер кавемгә Аллаһ зарар бирергә теләсә, ул зарарны тотып калучы юк, вә аларга Аллаһтан башка ярдәм бирүче хуҗа булмас”.** (“Әр-Рагд” сүрәсе, 10-11 нче аятьләр).

Гәбдуллаһ Ибн Гәббәс رضي الله عنهما әйткән: *“Бу фәрештәләр кешене алдан да, арттан да саклар, ә инде тәкъдирдә язылган килсә – кешене калдырып читкә китерләр”* – дигән.

Шулай ук, фәрештәләрдән – хөрмәтле язучылар, кешеләрнеӊ яхшы һәм начар гамәлләрен язып баралар. Аллаһ Тәгалә әйтте: **“Әлбәттә, шиксез, сезнеӊ өстегездә сакчы фәрештәләр бардыр. Алар Аллаһ каршында хөрмәтлеләр, сезнеӊ барча гамәлләрегезне язучылардыр. Сезнеӊ кылган эшләрегезне бик яхшы белүчеләрдер”.** (“Әл-Инфитар” сүрәсе, 10-12 нче аятьләр).

Шулай ук, фәрештәләрнеӊ саны иксез-чиксез күп, барысын Бер Аллаһ Үзе генә беләдер. Мисал өчен, пәйгамбәребез ﷺ үзенеӊ бер хәдисендә “күктә урнашкан “Әл-Бәйт әл-Мәгмүр”гә көн саен намаз укырга җитмеш меӊ фәрештә керә, һәм беренчеләре бүтән кирегә әйләнеп кайтмыйлар” дип әйтте.

Фәрештәләрнеӊ барлыгын инкяр иткән кеше барча мөселманнарның бердәм сүзе буенча көферлек кыла. Аллаһ Тәгалә әйтте: **“Берәү Аллаһка, аның фәрештәләренә, Китапларына, рәсүлләренә һәм ахирәт көненә көферлек кылса, ул кеше бик ерак адашу белән адашты”.** (“Ән-Нисә” сүрәсе, 136-нчы аять).

***<u>Күктән иңдерелгән Изге Китапларга иман:</u>***

Аллаһ Тәгалә һәрбер рәсүл белән китап иңдергән. Аллаһ Тәгалә әйтте: **“Рәсүлләребезне ачык аңлатмалар белән җибәрдек, вә аларга китаплар иңдердек, вә кешеләр гадел булсыннар өчен үлчәүне өйрәттек”.** (“Әл-Хәдид” сүрәсе, 25-нче аять).

---

[19] Бу аятьтән күрәбез – Аллаһ Тәгалә бу фәрештәне Үлем фәрештәсе дип атады, ягъни башка исем белән атамады. Шуңа күрә, бу фәрештәнеӊ кешеләр арасында таралган “Газраил” дигән исеме шик астында кала. Имам Ибн Кәсир үзенеӊ “Әл-Бидәя үән-Ниһәя” китабында бу исемгә Көрьәннән һәм хәдисләрдән ачык күрсәтмә юк диде.

Аллаһ Тәгалә, шулай ук, әйтте: **“Кешеләр һәммәсе дә ислам динендә иделәр, соңрак төрле диннәргә бүленделәр. Җәннәтләр белән сөендерүче һәм җәһәннәм газабы белән куркытучы итеп, Аллаһ пәйгамбәрләр җибәрде. Фикер каршылыкларында кешеләр арасын гаделлек белән хөкем итсеннәр өчен Аллаһ аларга хаклык белән китап иңдерде. Китапларында ислам дине ачык бәян ителгәннән соң диннең хөкемнәрендә фикер каршылыкларына Аллаһтан китап бирелгән кавемнәр генә аерылыштылар, бер-берләренә хөседлек һәм золымлык сәбәпле. Аллаһ Тәгалә Үзенең рөхсәте белән иманлы бәндәләрен фикер каршылыкларында хаклык ягына күндерде. Аллаһ Үзе теләгән кешене туры юлга салыр”.** (“Әл-Бәкъара” сүрәсе, 213-нче аять).

Аллаһ Тәгалә, шулай ук, әйтте: **“Әйтегез: “Аллаһка һәм үзебезгә иңдерелгән Коръәнгә һәм Ибраһим, Исмәгыйл, Исхак, Ягькуб пәйгамбәрләргә һәм аларның балаларына иңдерелгәнгә, Мусага бирелгән Тәүратка һәм Гайсәгә бирелгән Инҗилгә, һәм пәйгамбәрләргә Раббыларыннан бирелгәнгә ышандык һәм иман китердек, пәйгамбәрләрне берсен икенчесеннән аермыйбыз, барчасына бертигез ышанабыз, һәм Аллаһка итагать итеп, Аңарга буйсынабыз”.** (“Әл-Бәкъара” сүрәсе, 136-нчы аять).

Шулай ук: **“Йә иман китерүчеләр! Аллаһка, Аның рәсүленә, вә рәсүленә иңдергән Коръәнгә һәм әүвәл иңдерелгән китапларга хак иман белән ышаныгыз! Берәү Аллаһка, Аның фәрештәләренә, китапларына, рәсүлләренә һәм ахирәт көненә көферлек кылса, ул кеше бик ерак адашу белән адашты”.** (“Ән-Нисә” сүрәсе, 136-нчы аять).

Шулай ук: **“Һәм әйт: “Аллаһ иңдергән китапка иман китердем”.** (“Әш-Шүра” сүрәсе, 15-нче аять).

Шушы аятьләргә ияргән хәлдә, без бу китапларның барчасына да ышанабыз, аларның Аллаһтан иңдерелгән икәнлеген беләбез.

Аллаһ Тәгалә әйтте: **“Әлиф ләм мим. Коръәннең Аллаһтан иңдерелгән хак китап икәнлегендә һич шик юк, бу китап тәкъва мөэминнәргә хак юлны күрсәтүче һидәятдер. Ул тәкъва мөэминнәр кабердән кубарылуга, җәннәткә һәм җәһәннәмгә ышаналар, һәм намазларын тиешенчә үтиләр, һәм Без биргән байлыктан садака бирәләр. Алар сиңа (Мөхәммәд) һәм сиңа кадәр иңдерелгән китапларга иман китерәләр, һәм ахирәтнең хаклыгына инанганнар”.** (“Әл-Бәкъара” сүрәсе, 1-4 нче аятьләр).

Шулай ук, без – бу китаплар беркемнең дә сүзе түгел, ә бары Аллаһның Сүзе икәненә инандык, һәм Аллаһ Тәгалә бу китапларда әйтелгән белән хак һәм Үзе теләгән рәвештә сөйләште.

Мисал өчен, Аллаһ кайсыбер вакытта пәйгамбәрләр белән пәрдә аша турыдан-туры аралашты, мәсәлән, Муса пәйгамбәр عليه السلام белән: **“Муса вәгъдә кылынган урыныбызга килгәч, Раббысы аның белән сөйләште”.** (“Әл-Әграф” сүрәсе, 143-нче аять).

Шулай ук: **“Аллаһ Мусага әйтте: “Йә Муса! Кешеләргә илчелек кылуым һәм сөйләшүем аша сине башкалардан сайлап алдым”.** (“Әл-Әграф” сүрәсе, 144-нче аять).

Аллаһ Тәгалә башка вакытларда Үзенең Сүзен илче-фәрештәгә ишеттереп, аның аша илче-пәйгамбәргә җиткерә торган булды. Аллаһ Тәгалә әйтте: **“Аллаһ Тәгалә кешеләр белән сөйләшер булмады, мәгәр вәхий белән күңеленә салыр, яки күренмичә пәрдә аша сөйләшер, яки пәйгамбәргә фәрештә җибәреп Үзе теләгәнне вәхий белән иңдерер. Чынлыкта, Ул – Аллаһ бөек вә хикмәтледер”.** (“Әш-Шүра” сүрәсе, 51-нче аять).

Бу китапларга карата иманлы булу, халыкларга шул китаплар аша җиткерелгән шәригатьне дә кабул итеп, аңа буйсынып, шуның белән хөкем итүләрен таләп итә.

Шулай ук, бу китаплар бер-берсенең дөреслеген дә раслыйлар.

Соңрак иңдерелгән китаплар алдагы иңдерелгән китапларны гамәлдән чыгарулары да хактыр, мәсәлән, Инҗилнең Тәүраттагы кайбер хөкемнәрне бетерүе кебек. Аллаһ Тәгалә Гайсә пәйгамбәр عليه السلام турында әйтте: **“Миннән әүвәл иңдерелгән Тәүратта булганны раслаган хәлдә, һәм сезгә хәрам булган нәрсәләрнең кайберләрен хәләл иткәнем хәлдә, Раббыгыздан аятьләр белән сезгә пәйгамбәр булып килдем”.** (“Әли-Гыймран” сүрәсе, 50-нче аять).

Ә инде Көрьән – аннан алда иңдерелгән барча китапларны һәм шәригатьләрне гамәлдән чыгарды. Аллаһ Тәгалә әйтте: **“Без сиңа хаклык белән Коръәнне иңдердек, әүвәлге китапларны раслаганы һәм әүвәлге китапларның Аллаһ китаплары икәнлеге белән шәһадәт биргәне (яки алардан өстен булганы) хәлдә”.** (“Әл-Мәидә” сүрәсе, 48-нче аять).

Аллаһ, шулай ук, әйтте: **“Ул – Коръән барча галәмнәргә искәртүдер”.** (“Әл-Къаләм” сүрәсе, 52-нче аять).

Аллаһ Тәгаләнең Китапларына ышану – кайсылары турында гомуми рәвештә әйтелгән, шуңа иманны, ә кайсылары хакында җентекләп әйтелгән – шул өстәмәләргә дә иманны үз эченә ала.

Шул җентекләп әйтелгәннәрдән, мисал өчен, Аллаһ Тәгаләнең кайсыбер пәйгамбәрләренә иңдергән Китапларының атамаларын җиткерүе керә: Тәүрат – Муса пәйгамбәргә, Инҗил – Гайсәгә, Әз-Зәбүр – Дәвыд пәйгамбәргә һәм Көрьән – Мөхәммәд пәйгамбәргә иңдерелгән. Шулай ук, Муса һәм Ибраһим пәйгамбәрләргә аерым сәхифләр бирелүе дә искә алына. Барча пәйгамбәрләргә Аллаһның мактавы һәм сәламе булсын!

Ягъни, исемнәре аталган әлеге китапларның Аллаһ Тәгаләнең пәйгамбәрләренә җибәргән китаплар булуларына һәм, шулай ук, атамаларына дә иман китердек. Ә исемнәре билгеле булмаган китапларга, гомуми рәвештә, Аллаһ Тәгаләдән пәйгамбәрләргә килгән китаплар икәненә инандык. Аллаһ Тәгалә әйтте: **“Һәм әйт: “Аллаһ иңдергән китапка иман китердем”.** (“Әш-Шүра” сүрәсе, 15-нче аять).

Көрьән Кәрим – Аллаһ Тәгаләнең Үзенең пәйгамбәре Мөхәммәдкә ﷺ күктән иңдергән ахыргы китабы, аннан соң бүтән китаплар булмаячак. Һәм ул үзеннән алда килгән барча китапларны гамәлдән чыгарды, кешеләр һәм җеннәрнең барчасына да җибәрелде. Аллаһ Тәгалә әйтте: **"Ул – Корьән барча галәмнәргә искәртүдер".** ("Әл-Къаләм" сүрәсе, 52-нче аять). Кешеләрнең дөнья һәм ахирәт тормышларына нәрсә кирәк, барысын да үз эченә алды, Аллаһ Тәгалә әйтте: **"Бүген динегезне төзеп бетереп камил кылдым, бирәсе нигъмәтләремне дә сезгә тулысы белән җиткердем һәм риза булып ислам динен сезгә ихтыяр кылдым".** ("Әл-Мәидә" сүрәсе, 3-нче аять).

Шулай ук, Көрьән – Аллаһ Тәгаләнең могҗизасы, беркем дә бу китапка әз генә дә охшаш булган китап белән килә алмас: **"Әйт: "Әгәр кешеләр һәм җеннәр барчасы җыелып бер-берсенә ярдәмләшеп Корьәнгә охшаш бер китап иҗат итергә тырышсалар да, һич тә иҗат итә алмаслар".** ("Әл-Исра" сүрәсе, 88-нче аять). Шулай ук: **"Ул Корьәннең алдыннан да вә артыннан да батыл килмәс. Хикмәт Иясе һәм мактаулы булган Аллаһтан иңдерелгәндер".** ("Фуссыләт" сүрәсе, 42-нче аять).

Көрьәнне Аллаһ Тәгалә һәр үзгәртелүдән саклар, ягъни аңа ниндидер өстәүләр кертү яки киметүләр мөмкин түгел, Аллаһ Тәгалә әйткәнчә: **"Дөреслектә, Без Зекерне иңдердек һәм Без аны сакларбыз".** ("Әл-Хиҗер" сүрәсе, 9-нчы аять).

***<u>Аллаһ Тәгаләнең рәсүлләренә иман:</u>***

Моңа Аллаһ Тәгалә һәрбер өммәткә Аллаһның Үзенә генә гыйбадәт кылырга һәм Аннан башка затларга гыйбадәт кылудан ерак булырга чакыручы рәсүл җибәргәнен тану кирә. Бу рәсүлләр, дөрес сөйләүчеләрдән булып, ышанычлы, тәкъва, төпле, намуслы, туры юлдан баручы һәм туры юл күрсәткечләре булдылар. Аллаһның галәмнәрне искәртүен тулысы белән җиткереп бетерделәр.

Аллаһ Ибраһим пәйгамбәрне Үзенә "халил", пәйгамбәребез Мөхәммәдне дә ﷺ Үзенә "халил" итте, ягъни иң сөекле коллары итеп алды. Муса пәйгамбәр белән турыдан-туры сөйләште, Идрис пәйгамбәрне югары урынга күтәрде. Гайсә пәйгамбәр – Аллаһның колы һәм илчесе, "бар бул" дип Мәрьямгә әйткән сүзе, сайлап алынган һәм хөрмәтләнгән рәсүле булды.

Аллаһ пәйгамбәр-рәсүлләрне берсе-берсеннән өстен итеп дәрәҗәләрен күтәрде. Пәйгамбәребез Мөхәммәдне ﷺ Адәм балаларының иң хөрмәтлесе итте.

Диннең асылында аларның чакырулары бер булды: галәмнәр Раббысы, күркәм исем-сыйфатларга ия булуда һәм гыйбадәт кылуда Аллаһның берлеген җиткерү иде, Аллаһ Тәгалә әйткәнчә: **"Шиксез, Аллаһ хозурында ислам дине генә дин".** ("Әли-Гыймран" сүрәсе, 19-нчы аять).

Шулай ук: **"Берәү ислам диненнән башка дингә иярсә, аның дине вә гамәле һич кабул булмый, ул ахирәттә хәсрәтләнүче һәм югалтучыдыр".** ("Әли-Гыймран" сүрәсе, 85-нче аять).

Аллаһ Тәгалә Нух турында әйтте: **"Мин Аллаһтан мөселман булырга боерылдым".** ("Йунус" сүрәсе, 72-нче аять).

Аллаһ Тәгалә Муса турында әйтте: **“Йә каумем! Әгәр Аллаһка иман китереп мөселман булсагыз, Аңа гына тәвәккәл кылыгыз!”** (“Йуныс” сүрәсе, 84-нче аять).

Шулай ук, Аллаһ Тәгалә Бәлкыйсның сүзләрен китерде: **“Йә Раббым, үземә золым иттем, инде барча галәмне тәрбия итүче Аллаһка, Сөләйман белән бергә иман китереп, мөселман булдым”.** (“Ән-Нәмел” сүрәсе, 44-нче аять).

Шулай ук, Аллаһ Тәгалә әйтте: **“Без сезгә диндә шәригать төзеп бирдек, ул шәригатьне Нухка, вә сиңа, йә Мөхәммәд, иңдердек, вә Ибраһимгә, вә Мусага, вә Гайсәгә васыять иттек, Без төзегән шул хак дин шәригатен тотыгыз, вә төрле фиркаләргә бүленмәгез. Сезнең кешеләрне хак дингә чакыруыгыз мөшрикләргә бик авыр эш булды. Аллаһ Үзе төзегән хак дингә үзе теләгән кешесен ихтыяр итәр һәм анда тартыр, вә Аллаһка итагать белән кайткан кешене ул хак дингә күндерер”.** (“Әш-Шүра” сүрәсе, 13-нче аять).

Әбү Үмәмә һәм Әбү Зәрр китергән хәдисләрдә расланганча, рәсүлләрнең саны 315 булган, ә пәйгамбәрләрнең саны 124000 гә җиткән.

Пәйгамбәр белән рәсүлнең аермасы шундадыр: пәйгамбәргә Аллаһ вәхий иңдергән һәм бу пәйгамбәр шул вәхийне җиткерергә тиеш булган. Ә инде ул бу иңдерелгән белән Аллаһның әмерләренә карышучыларга җибәрелсә, ягъни аларга Аллаһның искәртүен җиткерүче булса, бу инде рәсүл була. Димәк, һәрбер рәсүл – пәйгамбәр, әмма һәрбер пәйгамбәр дә рәсүл түгел.

Аллаһ Тәгалә кайбер пәйгамбәр-рәсүлләрнең исемнәрен атады, мәсәлән, Әдәм, Нух, Идрис, Һүд, Салих, Ибраһим, Исмәгыйль, Исхак, Ягъкуб, Йосыф, Лүт, Шүгәйб, Йуныс, Муса, Һәрун, Ильяс, Зәкәрийә, Яхъя, Әл-Ясәг, Зүл-Кифел, Дәүд, Сөләйман, Әййүб, Ягъкубның уллары, Гайсә һәм Мөхәммәд, аларга Аллаһның мактавы һәм сәламе булсын! Һәм пәйгамбәрләр белән бәйле вакыйгаларны җиткерде, аларның тарихларында, әлбәттә, һәркемгә җитәрлек гыйбрәт һәм вәгазь бар: **“Без рәсүлләр җибәрдек, алдан инде сиңа хәбәрләрен бәян иттек, кайберләре турында сиңа сөйләмәдек, ә Аллаһ Муса белән камил сөйләшү белән сөйләште”.** (“Ән-Нисә” сүрәсе, 164-нче аять).

Шулай итеп, без барча пәйгамбәр-рәсүлләргә, гомуми рәвештә, иман китердек, ә инде берәрсе турында нindидер хәбәрләр тәфсилләп әйтелгән булса, шул өстәмәләргә дә инандык.

Шулай ук, без инандык, пәйгамбәр-рәсүлләр – кешеләр, Аллаһның бар иткән затлары, коллары. Аның хакимлегеннән һәм милкеннән бернәрсәгә дә ия түгелләр. Аллаһ Тәгалә әйтте: **“Әйт: “Мин сезнең кебек бер кешедер, миңа вәхий булды сезнең Иләһегез – бер генә Иләһ дип. Әгәр берәү Раббысын яхшы хәлдә очратуны өмет итсә, шул изге гамәлләр кылсын һәм Раббысына һичкемне дә шәрик-тиңдәш кылмасын!””** (“Әл-Кәһеф” сүрәсе, 110-нчы аять).

Аллаһ, шулай ук, әйтте: **“Аларга рәсүлләре әйтте: “Дөрес, без сезнең кебек кешеләрбез, ләкин Аллаһ Тәгалә бәндәләре арасыннан үзе теләгәненә нигъмәтен,**

**ягъни пәйгамбәрлекне бирә, без сезгә үзлегебездән аять-могҗиза китерә алмыйбыз, мәгәр Аллаһ теләге белән генә күрсәтәбез, мөэминнәр Бер Аллаһка гына тәвәккәл кылсыннар!”** (“Ибраһим” сүрәсе, 11-нче аять).

Аллаһ, шулай ук, әйтте: **“Синнән әүвәл җибәргән рәсүлләр ризык ашый вә базарларда йөри иделәр. Берегезне икенчегезгә фетнә кылдык – бәлки сабыр булырсыз, Раббың [хәлегезне] күрүче”.** (“Әл-Фүркан” сүрәсе, 20-нче аять).

Шулай ук: **“Әйт: “Мин сезгә әйтмимен Аллаһ хәзинәләре минем кулымда һәм яшерен нәрсәләрне беләмен һәм мин фәрештәмен” – дип. Мин, бары тик, миңа Аллаһтан вәхий ителгәнгә иярүчемен. Әйт: “Күрмәүче белән күрүче бертигез булырмы? Әллә фикерләп карамыйсызмы?”** (“Әл-Әнгәм” сүрәсе, 50-нче аять).

Шулай ук: **“Әйт: “Мин үземә файданы да вә зарарны да китерүче түгелмен, бәлки Аллаһ теләсә генә. Әгәр мин яшерен нәрсәләрне белә торган булсам, әлбәттә, үземә күп файдаларны булдырыр идем һәм миңа һичбер зарар ирешмәс иде. Мин бары [имансызларны] җәһәннәм белән кисәтүче вә мөэминнәрне җәннәт белән сөендерүчемен”.** (“Әл-Әграф” сүрәсе, 188-нче аять).

Без инандык, пәйгамбәрләр һәм рәсүлләр – Аллаһның илчелек белән хөрмәтләнгән коллары, шуңа күрә, Аллаһ Тәгалә аларны кол булуның иң югары дәрәҗәсе белән сыйфатлый һәм мактый.

Шулай ук, без инандык, Аллаһ илчелекне Мөхәммәд ﷺ белән тәмамлады һәм аны барча кешеләргә һәм җеннәргә җибәрде. Аллаһ Тәгалә әйтте: **“Әйт: Йә кешеләр! Чынлыкта, мин барчагызга – бөтен дөнья кешеләренә Аллаһның рәсүлемен”.** (“Әл-Әграф” сүрәсе, 158-нче аять).

Аллаһ, шулай ук, әйтте: **“Без сине галәмнәргә бары рәхмәт өчен генә җибәрдек”.** (“Әл-Әнбия” сүрәсе, 107-нче аять).

Аллаһ, шулай ук, әйтте: **“Без сине барча кешеләргә җәннәт белән шатландыручы вә җәһәннәм газабы белән кисәтүче итеп җибәрдек, ләкин күп кешеләр шуны белмиләр”.** (“Сәбә” сүрәсе, 28-нче аять).

Аллаһ Тәгалә барча пәйгамбәрләрдән килешү алганын хәбәр бирә – әгәр дә берәр пәйгамбәр заманында Мөхәммәд пәйгамбәр ﷺ җибәрелсә, шул пәйгамбәр Мөхәммәд пәйгамбәргә ﷺ иярергә тиеш булган. Шуннан, ачык рәвештә, күрәбез – Мөхәммәд пәйгамбәрнең ﷺ илчелеге ахыргы һәм тәмамлаучы, алдан килгән илчелекләрне гамәлдән чыгаручы. Аллаһ Тәгалә әйтте: **“Менә Аллаһ пәйгамбәрләрдән килешү алды: Мин сезгә Китап һәм хикмәт бирермен, әгәр дә шуннан соң, сездә булганны исбатлаучы рәсүл сезгә килсә, әлбәттә, аңа иман китерерсез һәм ярдәм итәрсез”. Аллаһ әйтте: “Моны раслыйсызмы һәм минем килешүемне кабул итәсезме?” Әйттеләр: “Без раслыйбыз һәм кабул итәбез”. Аллаһ әйтте: “[Килешүебезгә] шаһит булыгыз! Мин дә сезнең белән бергә шаһитләрдәнмен”. Кемнәр моннан соң читкә борыла, шулар фасыйклардыр”.** (“Әли-Гыймран” сүрәсе, 81-82 нче аятьләр).

Барча рәсүлләр дә, аларга Аллаһның мактавы һәм сәламе булсын, Мөхәммәд пәйгамбәр ﷺ киләчәге белән сөендерә торган булганнар. Аллаһ Тәгалә әйтте: **“Мәрьям улы Гайсә әйтте: “Йә Бәнү Исраил, мин сезгә Аллаһтан җибәрелгән рәсүлмен, миннән элек иңдерелгән Тәүратны раслаганым һәм миннән соң килә торган рәсүл белән сөенеч биргәнем хәлдә – аның исеме Әхмәд (Мөхәммәд). Гайсә пәйгамбәр аларга аятьләр вә могҗизалар белән килгәч, бу ачык сихер диделәр”.** (“Әс-Сафф” сүрәсе, 6-нчы аять).

Аллаһ, шулай ук, әйтте: **“Я Рабби! Безгә һидәятле күркәм тормышны насыйп ит! Һәм ахирәттә күркәм тормышны бир! Без хөкемнәреңә итагать итеп Сиңа кайттык (тәүбәгә килдек)! Аллаһ Тәгалә әйтте: “Үзем теләгән кешегә газабымны ирештерермен, ә рәхмәтем һәрнәрсәне чолгап алган. Ул рәхмәтебезне тәкъва булучыларга, зәкятләрен бирүчеләргә һәм Безнең аятьләребезгә иман китерүчеләргә бирербез. Алар рәсүлгә – укый-яза белмәгән пәйгамбәргә ияреләр, аның турында Тәүратта һәм Инҗилдә язмалар табырлар. Ул аларны гөнаһлы эшләрдән тыяр вә саваплы эшләргә өндәр, яхшы-пакъ нәрсәләрне аларга хәләл кылыр, зарарлы-пычрак нәрсәләрне хәрам кылыр, аларда булган авырлыкны вә диннәрендәге каты хөкемнәрне бетерер, рәсүлгә ышанып, аны хөрмәтләсәләр вә аңа ярдәм итсәләр һәм ул китергән һидәят яктылыгы булган Коръән хөкемнәренә иярсәләр, алар – өстенлек табучылар”.** (“Әл-Әграф” сүрәсе, 156-157 нче аятьләр).

Имам Мөслимнең “Сахих” хәдисләр җыентыгында Әбү Һүрайрадан رضي الله عنه хәдис килә, пәйгамбәребез ﷺ әйткән: ***“Мөхәммәднең җаны Кулында булучы*** (ягъни Аллаһ) ***белән ант итәмен – бу өммәттә кем генә булмасын, яһүдийме яки насранийме, әгәр минем турында ишетсә, аннан миңа иңдерелгәнгә иман китермичә вафат булса, ул Ут әһелләреннән булачак”*** – дигән.

Шулай ук, әгәр дә берәү Мөхәммәднең ﷺ барча кешелеккә җибәрелгән рәсүл икәнен инкяр итсә, шул барлык пәйгамбәр-рәсүлләргә карата көферлек кылучы булыр, хәтта үзен берәр пәйгамбәргә ышанучы һәм иярүче дип атаса да, шул пәйгамбәргә карата да көферлек кылган булыр. Аллаһ Тәгалә әйтте: **“Нух кавеме рәсүлләрне ялганга тоттылар”.** (“Әш-Шүгара” сүрәсе, 105-нче аять). Нух عليه السلام алдыннан рәсүлләр булмаса да, Аллаһ Тәгалә аны ялганга тоткан кавемне бөтен рәсүлләрне дә ялганга тоту дип атады.

Мөхәммәд ﷺ – ахыргы пәйгамбәр, аннан соң пәйгамбәрләр булмаячак. Шуңа күрә, берәр кем пәйгамбәрлеккә дәгъва итә икән, шул көферлек кылучы булыр. Аллаһ Тәгалә әйтте: **“Мөхәммәд ирләрегезнең атасы булмады, ләкин ул Аллаһның рәсүле вә пәйгамбәрләрнең ахыргысыдыр”.** (“Әл-Әхзәб” сүрәсе, 40-нчы аять).

Имам Мөслимнең “Сахих” хәдисләр җыентыгында Әбү Һүрайрадан رضي الله عنه хәдис килә, пәйгамбәребез ﷺ әйткән: ***“Миңа башка пәйгамбәрләрдән алты нәрсәдә өстенлек бирелде: миңа “җәвәмигүль-кәлим”*** [20] ***бирелде; дошманнарыма миннән курку белән миңа ярдәм күрсәтелде; ганимәт малы миңа рөхсәт ителде; барча җир***

---

20 “Җәвәмигүль-кәлим” – пәйгамбәребезгә ﷺ хас булган аз сүзләргә тирән һәм киң мәгънә сала белү сыйфаты.

***минем өчен чистарыну һәм намаз уку урыны кылынды; мин барча халыкларга җибәрелдем; минем белән пәйгамбәрләр тәмамланды”*** – дигән.

Берәр кем берәр пәйгамбәрне яки рәсүлне ялганга чыгара икән, шул, барча мөселманнарның бердәм сүзе буенча, көферлеккә чыга. Аллаһ Тәгалә әйтте: **“Аллаһка һәм рәсүлләренә көферлек күрсәтүчеләр Аллаһ белән Аның рәсүлләре арасын аерырга телиләр: “Рәсүлләрнең кайберләренә ышанабыз, кайберләренә ышанмыйбыз” – диләр. Һәм алар ышану белән ышанмау арасын юл итеп алырга омтылалар. Алардыр хак имансызлар, һәм имансызларга хур кылучы газапны әзерләдек. Аллаһка һәм рәсүлләренә иман китерүчеләр һәм рәсүлләрнең арасын аермаучылар – аларга тиздән әҗерләрен бирербез. Аллаһ – ярлыкаучы һәм рәхмәт кылучы”.** (“Ән-Нисә” сүрәсе, 150-152 нче аятьләр).

***<u>Кыямәт көненә иман:</u>***
Сөннәт һәм Җәмәгать әһелләре Кыямәт көне булачагына, анда булачак төрле хәлләр һәм вакыйгаларга бер шиксез инанганнар. Аллаһ Тәгалә әйткәнчә: **“Һәм алар ахирәткә һичшиксез инанганнар”.** (“Әл-Бәкъара” сүрәсе, 4-нче аять).

Аллаһ, шулай ук, әйтте: **“Аллаһ – Аннан башка хак иләһ юк. Кыямәтнең булачагында һич тә шик юк, ул көндә Аллаһ, әлбәттә, сезне хөкем итер өчен җыяр. Аллаһтан да дөресрәк сөйләүче булырмы?”.** (“Ән-Нисә” сүрәсе, 87-нче аять).

Аллаһ, шулай ук, әйтте: **“Әлбәттә, Кыямәт көне киләчәк, син аларны күркәм рәвештә гафу ит”.** (“Әл-Хиҗер” сүрәсе, 85-нче аять).

Кыямәт көненә ышануның бер өлеше булып, мәетләрнең терелеп, каберләреннән кубарылып чыгуларына ышану кирә. Аллаһ Тәгалә әйтте: **“Әгәр сурга өрелсә, җирдә вә күкләрдә булган һәр җан иясе үләр яки һушсыз булыр, мәгәр Аллаһ теләгән затлар үлмәсләр. Соңрак тагын бер мәртәбә өрелгәч, һәммәсе каберләреннән чыгып басып торырлар һәм күзәтерләр”.** (“Әз-Зүмар” сүрәсе, 68-нче аять).

Аллаһ, шулай ук, әйтте: **“Без әүвәл башлап халык кылганыбыз кебек һәрнәрсәне яңадан әүвәлге сурәтенә кайтарырбыз, бу Безнең өстебезгә алган хак вәгъдәдер, әлбәттә, Без моны эшләрбез”.** (“Әл-Әнбия” сүрәсе, 104-нче аять).

Кыямәт көненә ышануның тагын бер өлеше булып, бу көндә кешеләрнең уң кулларына яки артларыннан сул кулларына биреләчәк гамәл дәфтәрләренә ышану кирә.

Аллаһ Тәгалә әйтте: **“19. Әммә гамәл дәфтәре уң кулына бирелгән кеше: “Йә җәмәгать, килегез, минем гамәл дәфтәремне укыгыз, 20. мин әлбәттә дөньяда белдем бүген хисабка киләчәгемне” – дияр. 21. Ул кеше, риза булырлык, яхшы тереклектә, 22. бөек дәрәҗәле җәннәттә булыр. 23. Ул җәннәтләрнең җимешләре утырган вә яткан кешеләргә якындыр. 24. Ашагыз вә эчегез тәмләп ләззәт белән, үткән көннәрегезне изге гамәлләр кылып уздырганыгыз өчен! 25. Әмма гамәл дәфтәре сул кулына бирелгән кеше, әйтер: “Әгәр дә миңа гамәл дәфтәрем бирелмәгән булсамчы! 26. Хисабымны нинди икәнен белмәгән булсамчы! 27. Ни үкенеч, үлем белән бар да тәмамланган булса иде! 28. Инде миңа малым һич файда**

**бирмәде. 29. Хакимлегем дә һәлак булды!” 30. Аллаһ газап фәрештәләренә әйтер: “Тотыгыз ул кешене, богаулагыз аны! 31. Соңрак җәһәннәм утына атыгыз аны! 32. Соңрак аны җитмеш аршын озынлыктагы чылбыр белән урагыз! 33. Ул Бөек Аллаһка иман китермәде. 34. Вә мескеннәрне ашатырга чакырмады. 35. Бүген аның монда яраткан якын туганы юк. 36. Вә ризыгы да юктыр, мәгәр җәһәннәм әһленең тәннәреннән аккан эрен булыр. 37. Ул эренне мәгәр гөнаһлылар гына ашарлар”.** (“Әл-Хәкка” сүрәсе, 19-37 нче аятьләр).

Шулай ук, Кыямәт көненә иманның тагын бер өлеше булып, бу көндә куелачак үлчәүгә ышану кирә, һәм бер кемгә дә золымлык кылынмас. Аллаһ Тәгалә әйтте: **“Берәүнең үлчәүдә изгелеге авыр килсә, алар уңышка ирешүчеләр”.** (“Әл-Мөэминүн” сүрәсе, 102-нче аять).

Шулай ук, Кыямәт көнендә булачак шәфәгатькә инану тиешле. Аның берничә төре булачак:

- Бөек шәфәгать, мәхшәр мәйданында хисап тизрәк башлансын дип соралачак шәфәгать; бу бары пәйгамбәребез Мөхәммәдкә ﷺ генә хас;
- Җәннәт әһелләре анда барып ирешкәч, капкасы ачылсын дип соралачак шәфәгать; бу, шулай ук, пәйгамбәребез Мөхәммәдкә ﷺ генә хас;
- пәйгамбәребезнең ﷺ үзенең атасының абыйсы – Әбү Талиб өчен Җәһәннәмдә газабы җиңеләйтелсен дип кылыначак шәфәгате; бу да, әлбәттә, пәйгамбәребез ﷺ генә хас, һәм Әбү Талибның дөньяда вакытта пәйгамбәребезне ﷺ яклаганы һәм ярдәме сәбәпле булачак;
- кайбер Җәннәт әһелләренең Җәннәттәге дәрәҗәләре күтәрелсен дип кылыначак шәфәгать; монсы турында пәйгамбәребез ﷺ генә хас яки аңа гына түгел, башкаларга да биреләчәк дип әйтелде;
- олы гөнаһлар кылучылар өчен шәфәгать, ягъни зур гөнаһлар кылып вафат булган тәүхид-иман әһелләре өчен булачак шәфәгать – үзләренең гөнаһлары өчен Җәһәннәмгә кергәч, аннан чыгарылсыннар дип сорау; бу шәфәгать пәйгамбәребезгә ﷺ, башка рәсүлләргә, фәрештәләргә, тәкъвалы булып изгелек кылучыларга һәм яу кырында Аллаһ юлында вафат булганнарга биреләчәк. [21]

---

21 Әйтеп узырга кирәк, шәфәгать – тулысы белән Аллаһ Тәгалә милкендә, Аллаһ әйткәнчә: **“Әйт [йә, Мөхәммәд]: “Шәфәгать тулысы белән Бер Аллаһныкыдыр”** (“Әз-Зумар” сүрәсе, 44-нче аять). Аллаһ Тәгалә Үзенең милке белән Үзе теләгәнчә эш итәчәк, ягъни, бары Аның рөхсәте аша гына кемдер башка кеше өчен шәфәгать кылачак: **“Аның каршында Аның рөхсәтеннән башка кем шәфәгать кылыр икән?”** (“Әл-Бәкъара” сүрәсе, 255-нче аять). Шуңа күрә, “минем өчен Кыямәт көнендә шәфәгатьче бул” дип кабер әһелләренә һәм вафат булган әүлияләргә дога белән ялвару ширек гамәле булыр, Аллаһ Тәгалә әйтте: **“Алар Аллаһтан башка зарар вә файда китерә алмый торган затларга гыйбадәт кылалар һәм әйтәләр: “Болар Аллаһ каршында безнең шәфәгатьчеләребез”. Син аларга әйт: “Сез Аллаһка җирдәге вә күкләрдәге Үзе белмәгән нәрсәләрдән хәбәр бирәсезме? Ягъни Аның тиңдәше булып та Үзе белми, сез беләсезме? Аларның ширек кылуларыннан Аллаһ пакъ һәм бөектер”.** (“Йуныс” сүрәсе, 18-нче аять). Ягъни, “Йә Аллаһ, Кыямәт көнендә пәйгамбәребезнең ﷺ шәфәгатенә ирештерсәң иде” дип Аллаһның Үзеннән генә сорау тиешле.

Хәдисләрдән күренгәнчә, Кыямәт көнендә Көръән белән ураза да кеше өчен шәфәгатьче булырлар. Шулай ук, иман әһелләренең яшьли вафат булган балалары да әти-әниләре өчен шәфәгать кылырлар.

Шулай ук, Кыямәт көненә иманның тагын бер өлеше булып, пәйгамбәребезгә ﷺ биреләчәк сулыкка инану кирә. Аның суы – сөттән аграк, балдан татлырак, исе миск исеннән дә хушрак, кем аны эчә, шуны башка беркайчан да сусау басмаячак.

Кыямәт көненә иманның тагын бер өлеше булып, Җәһәннәм сыртыннан салынган Сырат күперенә инану кирә. Кешеләр, үзләренең бу дөньядагы гамәлләренә карап, аннан төрле рәвештә үтерләр: кемдер яшен, кемдер җил, кемдер кош тизлегендә. Пәйгамбәребез ﷺ Сырат күперенең икенче башында "Йә Раббым! Имин кыл!" дип ялварып торыр. Кайбер кешеләрнең гамәлләре шулай зәгыйфь булыр, хәтта бу күпердән шуышып кына барырлар. Ә күпернең як-ягында ыргаклар бар, әмер ителгән кешене эләктерерләр. Кемне тырнап кына алырлар, шул котылыр, ә кемне тотырлар, шул Җәһәннәмгә барып төшер.

Гомумән, Көръән белән Сөннәттә Кыямәт көне турында килүче барча хәбәрләргә инандык, Аллаһ Тәгалә шул вакытларда безләргә ярдәмен бирсә иде!

***<u>Тәкъдирнең яхшысына да, яманына да иман:</u>***
Сөннәт һәм Җәмәгать әһелләре Аллаһ Тәгалә барча мәхлукатның тәкъдирен алдан билгеләп куйганлыгына инанганнар. Аллаһ теләгән нәрсә генә булачак, теләмәсә – булмаячак. Аллаһ Тәгалә әйтте: **"Чынлыкта, Без һәр нәрсәне тәкъдир буенча бар кылдык".** ("Әл-Къамәр" сүрәсе, 49-нчы аять). Шулай ук, әйтте: **"Аллаһның әмере тәкъдир белән үтәлмеш булды".** ("Әл-Әхзәб" сүрәсе, 38-нче аять).

Тәкъдирнең дүрт дәрәҗәсе бар:

- <u>беренчесе</u>, гыйлем; без Аллаһ Тәгаләнең һәрнәрсәне чорнап алган гыйлеменә иман китердек, Ул алдан булганны, хәзергене һәм киләчәктә ничек булачагын белүче. Аның гыйлеменең башлангычы юк һәм ул мәңгелек, гыйлемсезлектән гыйлемгә яңарып тормый һәм онытылмый;

- <u>икенчесе</u>, язмыш; без Аллаһ Тәгалә Үзендә булган Китапта (Әл-Ләүхүл-Мәхфуз) Кыямәт көненә чаклы булачак барча нәрсәне язып куйганына иман китердек. Аллаһ Тәгалә әйтте: **"Әллә белмәдеңме Аллаһның җирдәге вә күкләрдәге нәрсәләрне белгәнлеген? Алар барчасы Ләүхүл-мәхфуздагы китапта язылмыш, бу Аллаһка бик җиңелдер".** ("Әл-Хәҗ" сүрәсе, 70-нче аять). Шулай ук, әйтте: **"Фиргавен әйтте: "Әүвәлдә үлеп киткән кешеләрнең хәлләре ничек?". Муса әйтте: "Аларның хәлләрен минем Раббым беләдер, Китапта язылмыш. Минем Раббым һич хаталанмый һәм бернәрсәне онытмый".** ("Таһә" сүрәсе, 51-52 нче аятьләр). Шулай ук, әйтте: **"Без һәрнәрсәне Төп китапта санап куйдык".** ("Йәсин" сүрәсе, 12-нче аять).

Моңа, шулай ук, күкләр һәм җир барлыкка китерелгәнче язылган тәкъдир керә. Аллаһ Тәгалә әйтте: **“Әйт: “Безгә Аллаһ тәкъдир кылганнан кала башка нәрсә ирешмәс”.** (“Әт-Тәүбә” сүрәсе, 51-нче аять).

Аллаһ Тәгалә барча кешелекне бу дөньяга җибәрер алдыннан бар кылып, үз-үзләренә карата шәһадәт китертеп, алардан килешү алган. Аллаһ Тәгалә әйтте: **“Янә хәтерләгез, Раббың Адәм балаларының аркасыннан балаларын алды вә бу эшкә үзләрен шаһит итте һәм әйтте: “Мин түгелме сезнең Раббыгыз?”. Алар әйттеләр: “Әлбәттә, Син безнең Раббыбыз”.** (“Әл-Әграф” сүрәсе, 172-нче аять).

Шулай ук, бала ана карынында булганда, фәрештә җибәрелеп аңа җан өрә һәм кешенең ризыгын, әҗәлен, гамәлләрен, бәхетсез яки бәхетле булачагын язып куя.

Тагын, Кадер кичәсендә киләсе бер елга тәкъдир билгеләнә. Аллаһ Тәгалә әйтте: **“Ул Кадер кичәсендә киләсе елга хәтле булачак эшләр хөкем ителер”.** (“Әд-Духан” сүрәсе, 4-нче аять). Ибн Гәббәс رضي الله عنهما исемле сахабә әйткән: *“Кадер кичәсендә Төп китаптан (Әл-Ләүхүл-Мәхфуз) алынып, алдагы елда буласы вакыйгалар языла – кемнеңдер вафат булуы яки тууы, ризык һәм яңгыр күләме, хәтта кемнеңдер Хаҗ кылуы язылыр, “фәлән-фәлән Хаҗ кылыр” дип әйтелер”.*

Һәм инде, көнлек тәкъдир дә языла. Аллаһ Тәгалә әйтте: **“Ул – Аллаһ һәр көнне эштәдер”.** (“Әр-Рахмән” сүрәсе, 29-нчы аять).

Көнлек тәкъдир – еллык тәкъдирнең тәфсиле, ягъни, җентекләп бирелүе, еллык тәкъдир – ана карынында язылган гомерлек тәкъдирнең тәфсиле, гомерлек тәкъдир – барча кешелек барлыкка китерелеп килешү алынылган тәкъдирнең тәфсиле, килешү тәкъдире – Аллаһның әмере буенча Каләмнең Төп китапта (Әл-Ләүхүл-Мәхфуздә) язганның тәфсиле. Ә инде, Төп китап – Аллаһның гыйлеменнән язылган.

- <u>өченчесе</u>, ихтыяр; күкләрдә һәм җирдә барча нәрсә Аллаһның ихтыяры, ягъни, теләге белән генә була, Аның ихтыярыннан башка һичнәрсә дә була алмый, Ул теләсә – була, теләмәсә – булмый. Аллаһ Тәгалә әйтте: **“Аллаһ бер нәрсәнең бар булуын теләсә, ул нәрсәгә фәкать “бар бул” дип әйтер һәм ул нәрсә бар булыр”.** (“Йәсин” сүрәсе, 82-нче аять).

  Шулай ук, әйтте: **“Әгәр Аллаһ теләсә иде, пәйгамбәрләрдән соң килгән кавемнәр, аларга ачык аңлатмалар килгәннән соң, бер-берләре белән сугышмас иделәр”.** (“Әл-Бәкъара” сүрәсе, 253-нче аять).

  Шулай ук: **“Әгәр Аллаһ теләсә, әлбәттә, аларның һәммәсен дә туры юлга җыяр иде”.** (“Әл-Әнгәм” сүрәсе, 35-нче аять).

  Шулай ук: **“Әгәр Раббың теләсә иде, бөтен кешеләрне бер өммәт кылыр иде”.** (“Һүд” сүрәсе, 118-нче аять).

  Шулай ук: **“Әгәр Без теләсәк, һәр кешегә һидаятне бирер идек, ләкин җен вә кешеләрнең имансызлары белән җәһәннәмне тутырачакмын дигән Минем сүзем хак булды һәм беркетелде”.** (“Әс-Сәҗдә” сүрәсе, 13-нче аять).

Шулай ук: **“Җирдә вә күкләрдә Аллаһны һичкем дә һичбер нәрсәдән көчсез итә алачак түгел. Аллаһ барча нәрсәне белүче вә һәр нәрсәгә көче җитүче”.** (“Фәтыр” сүрәсе, 44-нче аять).

- дүртенчесе, бар кылу; Аллаһ Тәгалә барча гамәл үтәүчене һәм аның гамәлен бар кылды, хәрәкәтләнүчене һәм аның хәрәкәтен бар кылды; тик торучыны да һәм аның тик торуын да бар кылды. Аллаһ Тәгалә әйтте: **“Аллаһ һәрнәрсәне бар итүче вә һәрнәрсә өстеннән кайгыртучы”.** (“Әз-Зүмар” сүрәсе, 62-нче аять).

Әмма, шуның белән бергә, Аллаһ колларының ниндидер гамәл кылуга көч-куәтләре һәм теләк-омтылышлары бар икәнлегенә дә без иман китердек. Аллаһ Тәгалә аларның үзләрен бар кылды, ихтыярларын, көч-куәтләрен, сөйләгән сүзләрен һәм эшләгән гамәлләрен дә бар кылды, ләкин сүзләре һәм гамәлләре кешеләрнең үзләренә кайтарыла, шулар өчен алар әҗер-савап яки җәза алачаклар.

Кешеләрнең көч-куәтләре Аллаһ аларга күпме мөмкинчелек биргән, шуннан чыкмый, һәм теләкләре дә Аллаһның теләгеннән уза алмый. Аллаһ Тәгалә әйтте: **“Чынлыкта, бу – искәртүдер. Теләгән кеше Раббысының җәннәтләренә бара торган туры юлны алсын! Әмма Аллаһ теләмәсә, сез дә тели алмассыз. Чынлыкта, Аллаһ һәрнәрсәне белүче вә хикмәт Иясе”.** (“Әл-Инсән” сүрәсе, 29-30 нчы аятьләр).
Шулай ук, әйтте: **“Бу – бары барча галәмнәргә искәртүдер. Сезләрдән туры юлга күнелергә теләге булган кешеләргә вәгазь һәм туры юлдыр. Туры юлга күнелүне тели алмассыз, мәгәр галәмнәр Раббысы Аллаһ теләсә генә”.** (“Әт-Тәкүир” сүрәсе, 27-29 нчы аятьләр).
Аллаһ Тәгалә, шулай ук, әйтте: **“Аллаһ Тәгалә һичкемне көче җитмәгән эш белән йөкләмәс. Берәү изге гамәлләр кылса – файдасы үзенәдер, әгәр берәү гөнаһларны, явыз эшләрне кәсеп итсә – газабы үзенәдер”.** (“Әл-Бәкъара” сүрәсе, 286-нчы аять).
Шулай ук, әйтте: **“Ошбу Җәннәтне сез кылган гамәлләрегез өчен мирас итеп алдыгыз”.** (“Әз-Зүхруф” сүрәсе, 72-нче аять). Ягъни, “гамәлләрегез сәбәпле”.
Шулай ук: **“Кылган гамәлләрегез өчен мәңгелек газапны татыгыз!”** (“Әс-Сәҗдә” сүрәсе, 14-нче аять).
Шулай ук: **“Берәү тузан бөртеге хәтле генә яхшылык кылган булса, аны күрер. Вә берәү тузан бөртеге хәтле генә начарлык эшләсә, аны күрер”.** (“Әз-Зәлзәлә” сүрәсе, 7-8 нче аятьләр).

Димәк, без инандык – язылган тәкъдир гамәл кылырга комачауламый, ягъни, тәкъдиргә генә тапшырылып, изге гамәлләрдән ваз кичү хаталы караш. Шуңа күрә, пәйгамбәребез ﷺ үзенең сахабәләренә тәкъдирнең һәм барча вакыйгаларның алдан язылуы һәм битләрдәге язмаларның кибеп бетүе турында хәбәр биргәч, сахабәләр пәйгамбәребездән ﷺ: *“Димәк, без тәкъдиребезгә таяныйк та, гамәлләрне калдырыйк?”* – дип сорау бирделәр, пәйгамбәребез ﷺ аларга: ***“Юк, гамәл кылыгыз, һәрберегезгә нәрсә язылган, шул җиңеләйтелер”*** – дигән. Аннан Аллаһның

шундый Сүзләрен укыган: **“5. Әмма бер кеше Аллаһ күрсәткән урыннарга садакалар бирсә һәм Аллаһтан куркып гөнаһлардан сакланса.**
**6. Һәм Аллаһның берлеген вә пәйгамбәрнең хаклыгын таныса.**
**7. Аңа җиңеллек вә рәхәтлек урыны булган Җәннәткә алып керүче гамәлләрне җиңеләйтербез.**
**8. Вә әмма бер кеше саранлык кылса, вә үзен Аллаһка вә ахирәт нигъмәтләренә мохтаҗсыз санаса, кирәксенмәсә.**
**9. Вә Аллаһның берлеген вә пәйгамбәрнең хаклыгын инкяр итсә.**
**10. Без аңа авырлык вә газап урыны булган Җәһәннәмгә алып керә торган гамәлләрне җиңеләйтербез”.** (“Әл-Ләйл” сүрәсе, 5-10 нчы аятьләр).

Шулай итеп, гамәл кылу – язылган тәкъдиргә илтүче сәбәп. Мисал өчен, дөньялыкта да ниндидер нәтиҗәгә ирешү өчен гамәл кылу кирәк: бала булсын өчен – никах, уңыш булсын өчен – җир сөрү, чәчү, эшкәртү эшләре һ.б. Нәкъ шулай ук, Җәннәткә керүгә – изге гамәлләр, ә Җәһәннәмгә – начар гамәлләр сәбәпче булып торалар.

**Иманның асылына карата дөрес инану.**

Сөннәт һәм Җәмәгать әһелләре иманның:

- калеб белән инанудан, ягъни, күңелдә шәһадәт сүзләрен хак рәвештә раслаудан;
- тел белән сөйләнгән сүзләрдән, ягъни, “Лә иләһә иллә-Ллаһ, Мүхәммәдүн расүлү-Ллаһ” дип шәһадәт китерүдән;
- тән белән гамәлләр кылудан төзелгәненә инанганнар.

Имам әш-Шәфиги رحمه الله әйткән: *“Сахабәләр һәм тәбигыйннәр, алардан соң килүчеләр һәм без очраткан [галимнәр] – барчасы да [шуңа] бердәм иделәр һәм әйттеләр: “Иман – сүзләр, гамәлләр, ниятләр, һәм берсесенең башкасыннан кала булуы җитми” – диделәр”.* Бу хәбәрне әл-Ләләкаи үзенең “Әс-Сөннәт” китабында китерә.

Шулай ук, иман – изге гамәлләр кылу белән арта, начар гамәлләр сәбәпле кими. Аллаһ Тәгалә әйтте: **“Үтеп баручы кәрван кешеләр мөселманнарга: “Мәккә мөшрикләре сезгә каршы күп гаскәр хәзерләгәннәр, куркыгыз алардан, сугышмагыз”, – диделәр. Бу сүзләр аларның иманнарын гына арттырды”.** (“Әли-Гыйимран” сүрәсе, 173-нче аять).

Шулай ук, әйтте: **“Хак мөэминнәр әнә шулардыр: кайчан Аллаһ зекер ителсә, күңелләре йомшарып, Аллаһтан куркырлар вә һәркайчан аларга Аллаһның аятьләре укылса, ул аятьләр аларның иманнарын арттырыр һәм алар һәрвакыт Раббыларына тәвәккәл кылырлар”.** (“Әл-Әнфәл” сүрәсе, 2-нче аять).

Шулай ук, әйтте: **“Әгәр Коръәннән бер сүрә иңдерелсә, монафикъларның кайберләре әйтәләр: “Бу сүрә кайсыгызның иманын арттырыр”, – дип көләләр. Әмма Коръәнгә ышанган кешеләргә сүрә иңү иманнарын арттыра һәм алар сүрә иңгәнгә шатланалар”.** (“Әт-Тәүбә” сүрәсе, 124-нче аять).

Аллаһ Тәгалә, шулай ук, әйтте: **“Мөэминнәр союздаш кабиләләрнең килгәнен күргәч: “Ошбу көн Аллаһ һәм Аның расүле вәгъдә иткән сынау көне вә ярдәм ирешәчәк көндер, Аллаһ вә Аның рәсүле вәгъдәләрендә тордылар” – дип әйттеләр. Һәм бу – мөэминнәрнең фәкать иманнарын һәм Аллаһның әмеренә буйсынуларын гына арттырды”.** (“Әл-Әхзәб” сүрәсе, 22-нче аять).

Шулай ук, әйтте: **“Ул – Аллаһ мөэминнәрнең күңелләренә тынычлык иңдерде, иманнары өстенә тагын иман өстәлсен өчен”.** (“Әл-Фәтх” сүрәсе, 4-нче аять).

Имам әл-Бохари һәм Мөслим үзләренең “Сахих” хәдисләр җыентыкларында Гәбдуллаһ ибн Гүмәр رضي الله عنهما исемле сахабәдән хәдис китерәләр, бервакыт пәйгамбәребез ﷺ хатын-кызларга вәгазь биргәндә аларга шундый сүзләр әйткән: ***“Акылыгызда һәм динегездә кимчелек булуына карамастан, төпле фикерле акыллы ирне гыйшык белән хуштан яздыручы башкаларны күргәнем юк”*** – дигән. Ягъни, диндә кимчелек булу иманда кимчелек булуны аңлата. Шулай ук, пәйгамбәребез ﷺ икенче бер хәдистә: ***“Иманы иң камил булган мөэмин – холкы иң яхшы булганы”*** – дип әйткән. Имам Әхмәд һәм башкалар Әбү Һүрайрадан китерәләр. Димәк, яхшы холыклы мөэмин иманы

тулы булу белән сыйфатлангач, начар холыклысы, киресенчә, иманында зәгыйфьлек һәм кимчелек булу белән сыйфатлана.

Иман, күңелдә игътикад булмыйча, сүздән һәм гамәлдән генә тора алмый, чөнки бу монафыйкларның иманы. Аллаһ Тәгалә әйтте: **“Мөселманнар арасында монафыйклар да бар, алар Аллаһка һәм ахирәт көненә ышандык диләр, ләкин үзләре ышанучы түгелләр”.** (“Әл-Бәкъара” сүрәсе, 8-нче аять).

Шулай ук, иман – танып белү генә дә түгел, чөнки бу имансызларның һәм инкяр итүчеләрнең ышануы. Аллаһ Тәгалә әйтте: **“Алар бу могҗизаларның Аллаһтан икәнлегеен инкяр иттеләр, ләкин күңелләре белән моны белә иделәр, золымлык вә тәкәбберлек белән”.** (“Ән-Нәмел” сүрәсе, 14-нче аять).

Шулай ук, әйтте: **“Алар сине ялганга чыгармыйлар, вә ләкин залимнәр Аллаһның аятьләрен инкяр итәләр”.** (“Әл-Әнгәм” сүрәсе, 33-нче аять).

Шулай ук, әйтте: **“Без Изге Китаплар биргән халыклар Мөхәммәдне үз балаларын таныган кебек таныйлар”.** (“Әл-Бәкъара” сүрәсе, 146-нчы аять).

Аллаһ Тәгалә, шулай ук, әйтте: **“Аларга үзләре белгән һәм таныган пәйгамбәр – Мөхәммәд ачык дәлилләр белән килгәч, аңа карата көферлек кылдылар”.** (“Әл-Бәкъара” сүрәсе, 89-нчы аять).

Шулай ук, иман – гамәл кылуны калдырып, сүзләр һәм калебтәге игътикад кына түгел. Чөнки, Аллаһ Тәгалә гамәлләрне “иман” сүзе белән атады. Аллаһ әйтте: **“Аллаһ сезнең иманыгызны югалтмас”.** (“Әл-Бәкъара” сүрәсе, 143-нче аять). Ягъни, “Бәйт әл-Мәкъдискә таба юнәлеп укыган намазларыгызны” дигән мәгънәдә. [22]

Имам әл-Бохариның һәм имам Мөслимнең “Сахих” хәдисләр җыентыкларында ибн Гәббәс رضي الله عنهما исемле сахабәдән килә, пәйгамбәребез ﷺ Гәбдүл-Къайс кабиләсеннән килгән делегациягә әйткән: ***“Мин сезгә дүрт нәрсәне әмер итәм: Аллаһка иман, беләсезме нәрсә ул Аллаһка иман? [Ул] – “Лә иләһә иллә-Ллаһ” дип шәһадәт китерү, намазны үтәү, зәкәт чыгару, Рамазан аенда ураза тоту һәм ганимәт малының биштән бер өлешен аерып бирү”*** – дигән.

Шулай ук, имам әл-Бохариның һәм имам Мөслимнең “Сахих” хәдисләр җыентыкларында Әбү Һүрайрадан رضي الله عنه риваять ителә, пәйгамбәребез ﷺ әйткән: ***“Иман җитмештән яки алтмыштан артык тармактан тора, иң яхшысы – “Лә иләһә иллә-Ллаһ” сүзләре, иң түбәне – юлда ятучы һәм үтергә комачаулаучы әйберне алып кую, оялчанлык та иманның бер тармагы”*** – дигән. [23]

---

[22] Мөселманнар башта Бәйт әл-Мәкъдискә (Иерусалим) таба юнәлеп намаз укыйлар иде. Аллаһ Тәгалә Мәккәдәге Кәгьбәтуллаһка юнәлеп намаз укырга боергач, кыйбла алмашылганчы вафат булган мөселманнарның намазлары белән нәрсә булыр дигән сорау бирелде. Шулчакта Аллаһ әлеге аятьне иңдерде һәм анда намазны “иман” сүзе белән атады. [“Тәфсир әл-Җәләләйн” китабын карарга була].

[23] Алдагы аятьтә Аллаһ Тәгалә намазны “иман” сүзе белән атады, ә китерелгән хәдисләрдә пәйгамбәребез ﷺ намазны, зәкәтне, уразаны, садаканы, юлда үтергә комачаулаучы әйберне алып куюны, шулай ук, “иман” диде. Ягъни, болар барысы да тән һәм мал белән кылына торган гыйбадәтләрнең иманның бер өлеше булуын күрсәтә.

Гамәл-гыйбадәтләр арасында намазны калдыру көферлек булып тора, ягъни, кем тулысы белән намазны калдырды, шул көферлек кылды. Бу – пәйгамбәребезнең ﷺ сахабәләренең бердәм фикере. 24

Тәкфир, ягъни көферлектә гаепләү – Аллаһның хакы, шуңа күрә, Аллаһ һәм Аның рәсүле ﷺ яки мөселманнар бертавыштан көферлеккә чыгарганнарны гына көферлектә гаепләргә була. Әгәр дә берәркем Көръәннән яки дөреслеге расланган хәдисләрдән, яки мөселман галимнәренең бердәм тавышыннан ачык дәлилләргә нигезләнмичә башка беркемне хаксызга көферлектә гаепли икән, бу кеше җитди җәза бирүгә һәм шелтәгә лаеклы. Имам әл-Бохари үзенең хәдисләр җыентыгында Сәбит ибн Даххәк رضي الله عنه исемле сахабәдән пәйгамбәребезнең ﷺ сүзләрен китерә: ***"Мөэминне көферлектә гаепләү аны үтерүгә тиң"*** – дигән.

Кеше – әйткән көфер <u>сүзләре</u> яки <u>гамәлләре</u> яки күңелендә йөрткән <u>игътикады</u> аркасында көферлеккә төшә ала. Һәм монда бу гамәлнең яки сүзләрнең яки игътикадның көферлек икәнен белеп, аның тыелган булуын тану шарт булып тормый.25

Шулай ук, <u>гомуми рәвештә</u> көферлеккә чыгару һәм <u>аерым шәхесне</u> көферлектә гаепләү арасын аерырга кирәк. Гомуми рәвештә көферлеккә чыгарганда "көферлек" сүзе гомуми рәвештә кулланыла: "бу гамәл яки сүз – көферлек", "мондый гамәлне эшләүче имансыз булып диннән чыга" дип әйтелә. Әмма инде, фәлән-фәлән исемле аерым шәхесне көферлектә гаепләүгә килгәндә, бу очракта барча шартлар җыелырга һәм көферлеккә чыгарырга комачаулаучы барча киртәләр алынырга тиешле. Ягъни, гомуми рәвештә көферлеккә чыгару һәрвакытта да аерым шәхесне көферлектә гаепләүгә китерә дигән сүз түгел. 26

---

24 Күрәбез, китапның авторы шәех Гәбдүссәләм намаз калдыру – олы көферлек дигән фикердә. Дәлил итеп, шәех бу фикерне пәйгамбәребезнең ﷺ сахабәләренең бердәм тавышы диде. Әйтеп узырга кирәк, бу мәсьәләгә карата элекке заманнан ук галимнәрнең сүзе бердәм түгел, кайбер галимнәр намазны калдыру кешене диннән чыгармый торган көферлек дип әйттеләр, мисал өчен бу – олы имамнар арасыннан, имам Әбү Хәнифәнең رحمه الله һәм аның мәзһәбе фикере. Ягъни, монда пәйгамбәребезнең ﷺ сахабәләренең бердәм сүзе булса, галимнәр арасында мондый фикер каршылыклары да булмас иде. Бу мәсьәлә, фикыһ китапларына юнәлеп, аерым фәнни тикшеренүгә мохтаҗ, тирәнтен кереп китапны озынайтасы килми. Әмма, һичшиксез, намазны калдыру шәригать текстларында "көферлек" төшенчәсе белән аталды һәм зур гөнаһ булып тора. Аллаһ Тәгалә әйтте: **"Сезне сакар җәһәннәменә нәрсә илтте? Алар әйтерләр: "Без намаз укучылардан түгел идек".** ("Әл-Мүддәссир" сүрәсе, 42-43 нче аятьләр). [Бу мәсьәлә турында тулырак мәгълүмат өчен "Хәшия ибн Гәбидин" 1/235, "Әл-фәтәүә әл-Һиндия" 1/50, "Мүгъни әл-мүхтәҗ" 1/327, "Әл-Мәҗмүг" 3/16, "Мүкъаддимәт ибн Рүшд" 1/64, "Әл-Мүкъниг" 1/307, "Әл-Инсаф" 1/402, "Мәҗмүгү әл-фәтәүә" 22/48, "Әс-саләтү үә хүкмү тәрикиһә" ибн әл-Къаййим һ.б. китапларны карарга була].

25 Мисал өчен, әгәр дә берәркем, мәҗбүр ителмәгән һәм хаталанмаган хәлдә, үз ирегe белән Аллаһ Тәгаләне яки Аның рәсүлен ﷺ яки Көръәнне мыскыллаучы сүзләр сөйләсә, хәтта уен-көлке итеп башкаларны көлдерер өчен булса да, мондый кеше көферлеккә төшә. Әмма, "фәлән кеше" шулай дип әйтте дип башка кешенең көфер сүзләрен гади тапшыру көферлек булып тормый. Аллаһ Тәгаләдән безләрне көферлек һәм ширекнең барча төрләреннән саклавын сорыйбыз! ["Дүрүсү фи шәрхи нәүәкъыдил-Ислам" 33, 139-140 китабын карарга була].

26 Монда аерым шәхесне көферлектә гаепләү дигәндә сүз – үзен мөселман дип атаучы, "Лә иләһә илләЛлаһ, Мүхәммәдүн расүлү-Лләһ" кәлимәсен шәһадәт китерүче, әмма нindидер көфер сүзләр әйтүче яки шундый гамәлләр кылучы яки көфер игътикад йөртүче кеше турында бара. Ә инде Ислам диненнән кала башка диндә булганнарны яки атеист-материалистларны гомуми рәвештә дә һәм =

## Олы гөнаһлар кылучыларның хөкеменә карата дөрес инану.

Сөннәт һәм Җәмәгать әһелләренең игътикадыннан – Аллаһ Тәгаләгә ширек кылудан кала башка барча гөнаһлар да мөселманны Ислам диненнән чыгармый икәнен белү, әгәр дә кеше бу гөнаһлар тыелмаган, рөхсәт ителгән дип санамаса. Ә инде берәр гөнаһны бу гөнаһ тыелмаган, рөхсәт ителгән дип эшләсә, яки, хәтта, эшләмәсә дә, әмма күңелендә шундый игътикад йөртсә – бу Көрьәнгә, Сөннәткә һәм мөселманнарның бердәм сүзенә карата көферлек кылу була, чөнки мондый кеше Көрьәнне, Мөхәммәд пәйгамбәрне ﷺ ялганга чыгара. [27]

Аллаһ Тәгаләгә ширек кылудан кала башка гөнаһлар кешене мәңгелеккә Җәһәннәм Утында калдырмый. Аллаһ Тәгалә әйтте: **“Аллаһ үзенә ширек кылуны гафу итмәс, башка гөнаһларны кемгә тели, шуңа гафу итәр”.** (“Ән-Нисә” сүрәсе, 48-нче аять), ягъни, бу аятьтән күрәбез: ширектән кала башка гөнаһлар кылучы Аллаһ Тәгаләнең ихтыярында – теләсә Үзенең юмартлыгы һәм рәхмәте белән бу кешене гафу итәчәк, теләсә – шул гөнаһлар бәрабәренә Җәһәннәмгә кертеп чистартачак, аннан, кешенең тәүхиде сәбәпле, аны Җәһәннәмнән чыгарачак һәм бу кеше Җәннәткә керәчәк.

Аллаһ Тәгалә Үзенең Китабында кайбер гөнаһларны искә алды, мисал өчен, кан коюю һәм золымлык, шул ук вакытта, бу гөнаһларны кылучы кешене “иман” сүзе белән сыйфатлады, ягъни, мондый кешеләр иманнары сәбәпле мөэминнәр, әмма гөнаһлары сәбәпле фәсыйклар. Аллаһ Тәгалә әйтте: **“Йә мөэминнәр, үтерелмеш кеше хакына сезгә кысас фарыз ителде: азат кеше өчен – азат кеше, кол өчен – кол, хатын-кыз өчен – хатын-кыз. Әгәр үтерүче кеше, үзенең кардәше тарафыннан гафу ителеп үлем җәзасыннан коткарылса, үтерүче кеше дә изгелеккә каршы изгелек итсен һәм үзе үтергән кешенең якыннарына үз ихтыяры белән тиешле кан хакын түләсен”.** (“Әл-Бәкъара” сүрәсе, 178-нче аять). Аллаһ Тәгалә мөэмин-мөселманнар арасыннан үтерүчене дә һәм үтерелмеш кешене дә “иман” төшенчәсе белән сыйфатлады, ягъни, иман сәбәпле “кардәшләр” диде.

---

аерым шәхесләрен дә көферлеккә чыгаруга бернинди дә киртә юк, чөнки алар, асылдан ук, Ислам динендә булуларына дәгъва кылмыйлар, шулай ук, Иблис, Фиргавен, Нәмруд, Къарун, Әбү Ләһәб һ.б. кебек аерым шәхесләргә карата да. Моңарга Көрьәннән, хәдисләрдән һәм мөселман галимнәренең бердәм тавышыннан ачык дәлилләр килә. [“Дүрүсү фи шәрхи нәүәкъыдил-Ислам” 79 китабын карарга була]. Шулай ук, әйтеп узырга кирәк, әгәр дә кеше үзен мөселман булуына дәгъва белдерсә дә, әмма, мисал өчен, үзе Аллаһның барлыгын инкяр итсә яки шикләнсә, яки Аллаһны, Аның рәсүлен ﷺ, Көрьәнне сүксә, яки “аны кем күреп кайткан” дип ахирәтне, Җәннәтне һәм Җәһәннәмне инкяр итсә, намаз укучылардан, ураза тотучылардан көлсә һ.б. шундый һәркемгә дә ачык билгеле көферлек кылса, мондый кешенең көферлектә булуына бер шик тә юк. Чөнки иман китергән кешедә Аллаһка, Аның рәсүленә ﷺ, Көрьәнгә, Аллаһның хөкемнәренә карата ярату, зурлау һәм хөрмәт бар. [Тулырак мәгълүмат өчен “Әл-Къаулүл-мүфид гәлә Китәби-т-тәүхид” 632-640 китабын карарга була. “Мүэссәсәтү әш-шәех Мөхәммәд ибн Салих әл-Гүсәймин әл-хайрия” нәшрияты].

27 Мисал өчен, әгәр дә берәркем хәмер эчә, әмма ул хәмернең тыелган икәнен таный икән – бу кеше олы гөнаһ кыла. Ә инде берәр кем хәмерне – Аллаһ аны тыймаган, рөхсәт иткән дип эчә икән, яки хәмерне бөтенләй эчмәсә дә, әмма шундый фикер йөртә икән, бу көферлек була. Чөнки, хәмер Көрьән аятьләре, дөрес хәдисләр һәм мөселманнарның бердәм сүзе белән тыелган. Ягъни, мондый кешенең көферлеккә төшүенең сәбәбе – хәмер эчү түгел, ә шундый игътикад йөртеп, Көрьәнне һәм хәдисләрне ялганга чыгару. [“Дүрүсү фи шәрхи нәүәкъыдил-Ислам” 180 китабын карарга була].

“Гөнаһ” сүзен гамәлгә карата да, аны кылучыга карата да кулланып, шул ук вакытта, ул кешене мөэмин-мөселман дип атау һәм аңа карата мөселман хөкемнәрен куллануда бернинди дә каршылык юк. Моны, ачык рәвештә, имам әл-Бохариның “Сахих” хәдисләр җыентыгында Гәбдуллаһ ибн Химәр رضي الله عنه исемле сахабәнең вакыйгасы күрсәтә. Гәбдуллаһ ибн Химәр хәмер эчә торган булган һәм аны пәйгамбәребез ﷺ янына алып килә торган булганнар. Шулай бервакыт, бер сахабә түзмәгән һәм: *“Аллаһ аны ләгънәт кылсын, инде күпме тапкыр шулай алып килергә була”* – дип әйткән. Шуннан пәйгамбәребез ﷺ: ***“Ләгънәт кылма аны, ул Аллаһны һәм Аның рәсүлен ярата”*** – дигән.

Ягъни, шушы олы гөнаһны эшләве аркасында ул Ислам диненнән чыкмады, киресенчә, пәйгамбәребез ﷺ аның иманы булуын раслады.

Шуны аңларга кирәк, “көферлек”, “ширек”, “золымлык”, “гөнаһ”, “нифакъ” [28] сүзләре шәригать текстларында ике мәгънәдә килергә мөмкин:

- беренчесе, “олы, зур” мәгънәсендә, ягъни, иманның нигезенә каршы килүе сәбәпле тулысы белән кешене диннән чыгаручы;
- икенчесе, “кече” мәгънәсендә, ягъни, иманның тулылыгына каршы килүче, әмма кешене диннән чыгармаучы.

Әлеге бүленеш тәкъва сәләфләрдән رضي الله عنهم килә. Мисал өчен, иң белемле сахабәләрнең берсе, Көръәнгә тәфсир бирүче – Гәбдуллаһ ибн Гәббәстән رضي الله عنهما көферлектән кече көферлек, золымлыктан кече золымлык, гөнаһтан кече гөнаһ, нифакътан кече нифакъ булуы риваять ителә.

Аллаһ Тәгалә Үзеннән башкаларга гыйбадәт кылучыны “имансыз”, “мөшрик”, “залим” дип атады:

Аллаһ әйтте: **“Берәү Аллаһ белән бергә башка иләһкә гыйбадәт кылса, аның бу эшенә һич дәлиле юктыр, аның хөкем ителеше фәкать Раббысы каршындадыр. Имансызлар уңышка ирешә алмаслар!”** (“Әл-Мөэминүн” сүрәсе, 117-нче аять).

Шулай ук, әйтте: **“Әйт: “Мин фәкать Аллаһка гына гыйбадәт кыламын, Аңарга һичкемне шәрик-тиңдәш кылмыймын””.** (“Әл-Җин” сүрәсе, 20-нче аять).

Шулай ук, әйтте: **“Сиңа файда да, зарар да китерә алмаган башка [иләһләргә] гыйбадәт кылма. Әгәр син бу эшләрне эшләсәң, әлбәттә, залимнәрдән булырсың”.** (“Йуныс” сүрәсе, 106-нчы аять).

Шулай ук, әйтте: **“Менә Без фәрештәләргә әйттек: “Адәмгә сәҗдә кылыгыз!” Һәм сәҗдә кылдылар, мәгәр Иблис сәҗдә кылмады, ул җеннән иде, Раббысының әмеренә карата гөнаһ кылды”.** (“Әл-Кәһеф” сүрәсе, 50-нче аять).

---

28 Нифакъ – монафыйклык, икейөзлелек.

Бу аятьләрдә “олы көферлек”, “олы ширек”, “көферлек мәгънәсендә олы золымлык”, “көферлек мәгънәсендә олы гөнаһ” турында сүз бара, ягъни, аларның иман белән бергә җыела алмый торган төрләре.

Аллаһ Тәгалә, шулай ук, әйтте: **“Берәү Аллаһ иңдергән хөкемнәр белән хөкем итмәсә, андый кешеләр имансызлар”.** (“Әл-Мәидә” сүрәсе, 44-нче аять).

Шулай ук, әйтте: **“Берәү Аллаһ иңдергән хөкемнәр белән хөкем итмәсә, андый кешеләр үз-үзләренә золым итүче залимнәр”.** (“Әл-Мәидә” сүрәсе, 45-нче аять).

Шулай ук, әйтте: **“Берәү Аллаһ иңдергән хөкемнәр белән хөкем итмәсә, андый кешеләр гөнаһлылар”.** (“Әл-Мәидә” сүрәсе, 47-нче аять).

Аллаһ Тәгалә, шулай ук, әйтте: **“Золымлык белән ятимнәр малын ашаган кешеләр, әлбәттә, карыннарына утны ашыйлар һәм бик тиз Җәһәннәм Утына керерләр”.** (“Ән-Нисә” сүрәсе, 10-нчы аять).

Пәйгамбәребез ﷺ әйткән: ***“Мөселманны яманлау – гөнаһ, ә аның белән сугышу – көферлек”*** – дигән. Башка бер хәдистә: ***“Кем Аллаһтан кала башка белән ант итте, шул көферлек яки ширек кылды”*** – дип әйткән.

Бу текстларда “кече көферлек”, “кече ширек”, “золымлык”, “гөнаһ” турында сүз бара. Көрьәннән һәм Сөннәттән, тәкъва сәләфләрнең бердәм сүзләреннән күренгәнчә, алар белән иман бергә җыела ала, әмма болар иманга кимчелек китерәләр һәм аның тулылыгына каршы киләләр. [29]

---

[29] Дөрес аңларга кирәк, бу бүлекнең игътикад китапларында килүенең сәбәбе гөнаһларны җиңеләйтеп күрсәтү түгел, ә мөселманнарны олы гөнаһлар кылганнары өчен көферлектә гаепләүче хариҗыйлар (хаүәриж) агымын инкяр итү, ягъни “кече көферлек”, “кече ширек”, “золымлык”, “гөнаһ” дигән сүзләр ниндидер җиңел нәрсәне күрсәтә дип уйлау бер дә ярамый. Мисал өчен, “кече көферлек”, “кече ширек” дигән төшенчәләрдә сүз, асылда, көферлекнең яки ширекнең Ислам диненнән чыгармый торган төрләре турында барса да, әмма алар барыбер олы гөнаһлар дәрәҗәсендә калалар. Ә кайбер очракларда, асылда кече көферлек яки кече ширек булган гамәл олы көферлеккә яки олы ширеккә әйләнергә мөмкин! Мисал өчен, Аллаһтан башка белән ант итү, бу, асылда – кече ширек, әмма берәркем шул ант иткән затны Аллаһны зурлаган кебек зурлау сәбәбендә шуның белән ант итә икән, бу гамәл олы ширеккә эверелә. [Бу бүлеккә карата тулырак мәгълүматны “Шәрх гәкыйдә әт-Тахавия” 252-260 китабыннан карарга була. “Дәрүл-хәдис әл-Къаһира” нәшрияты].

**Пәйгамбәребезнең ﷺ сахабәләренә карата дөрес инану.**

Сөннәт һәм Җәмәгать әһелләренең игътикадыннан – пәйгамбәребезнең ﷺ сахабәләрен ярату, аларга карата яхшы мөнәсәбәттә булу һәм ризалык белдерү, алар өчен Аллаһның ризалыгын һәм гафуын сорау, һәм аларны мактау тора. [30]

Аллаһ Тәгалә әйтте: **“Мәккәдән Мәдинәгә күчеп килгән беренче мөһаҗирләр һәм Мәдинәдәге беренче ансарлар – ярдәм итүчеләр, һәм аларга яхшы рәвештә ияргән башка мөселманнар – алардан Аллаһ риза булды һәм алар да Аллаһтан риза. Вә аларга асларыннан елгалар ага торган җәннәтләр хәзерләнде, алар анда мәңге калырлар. Бу – зур уңышка ирешүдер”.** (“Әт-Тәүбә” сүрәсе, 100-нче аять).

Аллаһ Тәгалә, шулай ук, әйтте: **“Агач төбендә сиңа бәйгать [31] биргән сахабәләрдән Аллаһ, һичшиксез, риза булды”.** (“Әл-Фәтх” сүрәсе, 18-нче аять). Әгәр дә, Аллаһ Тәгалә берәр кемгә Үзенең ризалыгын биргән икән, Ул бу кешегә беркайчан да ачулы булмаячак! Дөреслеге расланган хәдистә килгәнчә, пәйгамбәребез ﷺ әйткән: ***“Агач төбендә бәйгать биргәннәрдән берсе дә Җәһәннәм Утына кермәячәк”*** – дигән.[32] Алар арасында Әбү Бәкер, Гүмар ибн әл-Хаттаб, Гүсмән ибн Гәффән һәм Гәли ибн Әби Талиб кебек иң яхшы сахабәләр булуы билгеле.

Аллаһ Тәгалә Үзенең Китабында мөһаҗирләрне [33] искә ала һәм аларны “тугрылык” сыйфаты белән тасвирлый. Аллаһ Тәгалә әйтте: **“Җиңеллек белән алынган табыш малы, йортларыннан чыгарылып вә малларыннан аерылып дин өчен күчеп киткән мөһаҗирләрнең фәкыйрьләренә бирелер, ул мөһаҗирләр Аллаһның нигъмәтенә вә ризалыгына омтылалар, Аллаһ диненә вә Аның рәсүленә ярдәм бирәләр, әнә шулардыр тугрылар”.** (“Әл-Хәшер” сүрәсе, 8-нче аять).

Аннан соң, Аллаһ Тәгалә ансарларны [34] искә ала һәм әйтә: **“Ә Мәдинәдә төпләнгән һәм иманны алдан кабул иткәннәр күчеп килгән мөһаҗирләрне яраталар, вә аларга бирелгән табыш малы сәбәпле күңелләрендә ачу һәм хөсетлек тапмыйлар. Ул [ансарлар] үзләре мохтаҗлык кичерсәләр дә, башкаларга өстенлек бирәләр. Берәү нәфесенең саранлыгыннан сакланылса, алар – уңышка ирешүчеләр”.** (“Әл-Хәшер” сүрәсе, 9-нчы аять).

Аннан, Аллаһ Тәгалә сахабәләрдән соң килүче һәм аларның юлына яхшы рәвештә ияручеләрне искә ала, аларның хәлләрен җиткерә: **“Ә инде алардан соң килүчеләр әйтәләр: “Йә Раббыбыз, безне һәм бездән алдан иманга килгән кардәшләребезне гафу кыл, вә калебләребезгә иман китергән кешеләргә карата ачу вә хөсетлек салма! Йә Раббыбыз, Син – шәфкатьле һәм рәхимлесең!””.** (“Әл-Хәшер” сүрәсе, 10-нчы аять).

---

30 “Сахабә” дип пәйгамбәребезне ﷺ очраткан, аңа иман китергән һәм иманлы хәлдә вафат булган кешеләрне атыйлар. [Ибн Хәҗәр әл-Гәскъаләни, "Әл-исабә фи тәмйиз әс-сахабә", 1/10].

31 Ант, присяга.

32 Хәбәрләрдә бу вакытта анда якынча 1500 сахабә булганы хәбәр ителә! [“Тәфсир әс-Сәгди”, 806. “Мүнтәдә ас-Сәкъафә” нәшрияты].

33 Мөһаҗирләр – Мәккәдән Мәдинәгә һиҗрәт кылып күчеп килгән сахабәләр.

34 Ансарлар – Мәдинәдә яшәүче, күчеп килгән мөһаҗирләрне кабул иткән сахабәләр.

Аллаһ Тәгалә, шулай ук, әйтте: **“Мөхәммәд – Аллаһның рәсүле, аның белән булган мөэминнәр имансызларга карата катылар вә бер-берләренә – рәхимлеләр, күрерсең аларны – рөкугъ-сәҗдә кылып Аллаһның нигъмәтен вә ризалыгын алырга омтылырлар, аларның йөзләрендә намаз укуларының галәмәте булыр. Бу сыйфатлары Тәүратта да әйтелгәндер. Ә инде Инҗилдәге сыйфатлары – тармакларын чыгаручы иген кебек, ул тармак игенгә куәт бирде, һәм ул иген калынайды вә тураеп камылына басты, бу хәл игенчеләрне гаҗәпләндерер. Аллаһ шулай кылды, сахабәләрнең хәлен күреп имансызларның ачуын чыгарыр өчен. Иман китереп изге гамәлләр кылучыларга Аллаһ Үзенең мәгъфирәтен һәм бөек әҗерләрен вәгъдә итте”.** (“Әл-Фәтх” сүрәсе, 29-нчы аять).

Имам Мәлик رحمه الله әйткән: *“Кем калебендә пәйгамбәребезнең ﷺ сахабәләренең берәрсенә карата ачу-нәфрәт таба, бу аятьтә әйтелгән аңа кагыла”* – дигән.

Аллаһ Тәгалә, шулай ук, әйтте: **“Иман китергән вә дин өчен һиҗрәт кылган вә Аллаһ юлында көрәшкән, һәм, шулай ук, күчеп килгән мөэминнәрне өйләренә кабул иткән һәм ярдәм күрсәткәннәр – алардыр хак мөэминнәр, аларга мәгъфирәт вә мул өлеш әзерләнде”.** (“Әл-Әнфәл” сүрәсе, 74-нче аять).

Аллаһ Тәгалә сахабәләрнең бөек дәрәҗәләре турында бәян итә, аларның җиңү килгәнче дә, ягъни, Худәйбия солыхы төзелгәнче, һәм җиңүдән соң да Аллаһ юлында малларын сарыф итүчеләренә һәм Аның юлында көрәшүчеләренә – барчасына да – Үзенең Җәннәтен вәгъдә итте: **“Сезләрдән җиңү килгәнче малын Аллаһ юлына биргән һәм Аллаһ юлында көрәшкән кеше, бу эшләрне җиңү килгәннән соң эшләгән кешеләр белән бертигез булмас, беренчеләренең дәрәҗәләре алардан соң малын биреп Аллаһ юлында көрәшкән кешеләрдән олугърактыр. Әмма Аллаһ аларның барчасына да җәннәтне вәгъдә кылды, вә Ул – Аллаһ сезнең кылган эшләрегезне белүчедер”.** (“Әл-Хәдид” сүрәсе, 10-нче аять). [35]

Имам әл-Бохариның һәм имам Мөслимнең “Сахих” хәдисләр җыентыкларында Әбү Сәгид әл-Худри رضي الله عنه исемле сахабәдән килә, ул әйткән: *“Аллаһ илчесе ﷺ әйтте:* ***“Минем сахабәләремне сүкмәгез”*** – диде. Ә имам Мөслимнең риваятендә: ***“Минем сахабәләремнең берсен дә сүкмәгез, әгәр дә берәрегез Үхүд тавы зурлыгында алтынны садака итеп бирсә дә, бу сахабәләремнең мүдд яки аның яртысы күләмендәге садакаларына да тормый”*** – дигән.

Мүдд – кулы уртача зурлыктагы ир-атның берләштерелгән ике учына сыярлык бөртекле җисемнәрне үлчәү берәмлеге. Ягъни, сахабәләрнең дәрәҗәләре башкалардан шуның хәтле югары булуы сәбәпле, аларның берләштерелгән ике уч яки бер генә уч күләмендәге биргән садакалары калганнарның Үхүд тавы зурлыгындагы алтынны садака итеп бирүләреннән дә өстенрәк!

---

[35] Күрәсең, кадерле укучым, Аллаһ Тәгалә бу аятьтә сахабәләрнең әүвәлгеләренә дә һәм ахыргыларына да Җәннәтне вәгъдә итте. Шуңа күрә, сахабәләргә карата нindидер начар фикер йөртү яки аларга тел-теш тидерү Җәннәт кешеләренә карата золымлык булып торыр. Ә Җәннәт кешеләренә карата золымлык кылучы кешенең урыны шулай ук Җәннәт булырмы икән?! Бу турыда фикерлә!

Имам әл-Бохариның һәм имам Мөслимнең “Сахих” хәдисләр җыентыкларында Гыймран ибн Хусайн رضي الله عنه исемле сахабәдән килә, пәйгамбәребез ﷺ әйткән: ***“Иң хәерле кешеләр – минем буын, аннан алардан соң килүчеләр, аннан боларыннан соң килүчеләр”.*** Гыймран әйткән*: “Ул үзенең буын кешеләреннән соң тагын икене, әллә өч буынны әйтте”* – дигән. Аннан пәйгамбәребез ﷺ дәвам иткән: ***“Шуннан соң килер кавем – алардан шәһадәт сорамасалар да, шәһадәт китерергә ашкынырлар; хыянәтле һәм ышанычсыз булырлар; нәзерләр әйтерләр, ләкин үтәмәсләр; һәм алар арасында юан-тазалар күп булыр”*** – дигән.

Шулай ук, ике «Сахих»та Әнәс ибн Мәликтән رضي الله عنه риваять ителә, пәйгамбәребез ﷺ әйткән: ***“Иманның билгесе булып ансарларны ярату, ә монафыйклыкның билгесе – ансарларга нәфрәт тора”*** – дигән.

Тагын ике «Сахих»та Әл-Бәра ибн Гәзиб رضي الله عنه исемле сахабәдән риваять ителә, пәйгамбәребез ﷺ ансарлар турында әйткән: ***“Аларны мөэминнәр генә яратыр һәм монафыйклар гына яратмас, кем аларны ярата – шуны Аллаһ яратыр, ә кем аларга нәфрәт күрсәтә – шуңа Аллаһ нәфрәтләнер”*** – дигән.

Имам Мөслимнең “Сахих” хәдисләр җыентыгында Әбү Һурайра һәм Әбү Сәгидтән رضي الله عنهما хәдис килә, пәйгамбәребез ﷺ әйткән: ***“Аллаһка һәм ахирәт көненә иман китергән кеше ансарларга карата нәфрәт кичермәс”*** – дигән.

Имам әл-Бохариның һәм имам Мөслимнең “Сахих” хәдисләр җыентыкларында Гәли ибн Әби Талибтан رضي الله عنه риваять ителә, пәйгамбәребез ﷺ Хәтыб ибн Әби Бәлтәгәһ исемле сахабә вакыйгасында аның турында болай дигән: ***“... Ул бит Бәдер сугышында катнашты. Каян беләсең син, бәлки Аллаһ Бәдер сугышында катнашучыларга караган да,*** **“Ни теләсәгез шуны эшләгез, Мин сезне инде гафу иттем”** ***дип әйткәндер”*** – дигән.

Шулай ук, Сөннәт һәм Җәмәгать әһелләре шуңа инанганнар – пәйгамбәребездән ﷺ соң бу өммәттә иң хәерле кеше – Әбү Бәкер әс-Ситдыйк, аннан – Гүмар әл-Фәрукъ. Моңа карата сахабәләр һәм тәбигыйннәр бердәм сүздә, берсесеннән дә каршы фикер килми. Мөэминнәрнең әмире хәлиф Гәли ибн Әби Талибтан رضي الله عنه күп төрле юллар белән шундый сүзләр җиткерелә, ул әйткән: *“Пәйгамбәребездән соң бу өммәтнең иң хәерлесе – Әбү Бәкер, аннан – Гүмар”* – дигән.

Аларның икесеннән соң Сөннәт һәм Җәмәгать әһелләре Гүсмән ибн Гәффәнне, аннан – Гәли ибн Әби Талибны атыйлар. Аллаһ Тәгалә барлык сахабәләрдән дә разый булсын!

**<u>Пәйгамбәребезнең ﷺ гаилә әһелләренә (әһлү-л-бәйт) карата дөрес инану.</u>**

Сөннәт һәм Җәмәгать әһелләренең игътикадыннан – пәйгамбәребезнең ﷺ гаилә әһелләрен ярату, югары дәрәҗәләрен танып, аларны ихтирам итү тора. Бу – пәйгамбәребезнең ﷺ Гъадир Хумм [36] көнендә калдырган васыяте: Аллаһ Тәгаләне мактап, Аны зурлагач, вәгазь сөйләп кешеләрне искәрткәннән соң, болай дип әйткән: ***"Һәм аннан соң: йә җәмәгать, мин дә кеше затыннан, озакламый миңа да Аллаһның илчесе килер һәм мин аңа җавап бирермен.*** [37] ***Сезгә ике кыйммәтле әйбер калдырам: беренчесе, Аллаһның Китабы, анда туры юл һәм нур, Аллаһ Китабын алыгыз һәм аңа ныклап ябышыгыз".*** *Шуннан пәйгамбәребез ﷺ кешеләрне Аллаһ Китабына иярергә җәлеп иткән һәм дәртләндергән, аннан әйткән:* ***"[Икенчесе], минем гаилә әһелләрем. Аларга карата сезгә Аллаһны исегезгә төшерәм! Аларга карата сезгә Аллаһны исегезгә төшерәм! Аларга карата сезгә Аллаһны исегезгә төшерәм!"*** [38] Хәдисне имам Мөслим үзенең "Сахих"ында Зәйд ибн Әркъам رضي الله عنه исемле сахабәдән китерә.

Хәфиз ибн Кәсир رحمه الله үзенең "Тәфсир" китабында әйткән: *"Пәйгамбәребезнең ﷺ гаилә әһелләренә карата булган васыятьне без кабул итәбез, аларга яхшы мөгамәлә кылабыз, ихтирам итәбез һәм хөрмәтлибез. Алар, чыгышлары һәм нәселләре белән, иң саф һәм җир йөзендә яшәгән иң яхшы йорттан чыккан кешеләр. Бигрәк тә, пәйгамбәребезнең ﷺ ачык һәм күркәм Сөннәтенә ныклап ябышучы булсалар. Ата-бабалары әл-Гәббәс һәм аның балалары, Гәли, аның гаилә әһелләре һәм нәсел-токымы кебек. Аллаһ Тәгалә аларның барчасыннан да разый булсын!".*

Пәйгамбәребезнең ﷺ гаилә әһелләренә, шулай ук, аның хөрмәтле хәләл җефетләре керә. Аллаһ Тәгалә аларга мөрәҗәгать итеп әйтте: **"Вә өйләрегездә торыгыз, вә, җаһилият заманындагы хатыннар кебек, бизәкләнгән зиннәтләрегезне ят ирләргә күрсәтмәгез, намазларыгызны укыгыз, зәкәтләрегезне бирегез, вә Аллаһка вә Аның рәсүленә итагать итегез. Йә рәсүлнең гаилә әһелләре, Аллаһ сездән гөнаһларны күтәрүне вә сезне кимчелекләрдән пакълауны телидер. Өегездә укылган Аллаһның аятьләрен вә Хикмәтне зекер итегез, Аллаһ – йомшаклык Иясе һәм һәрнәрсәдән хәбәрдар".** ("Әл-Әхзәб" сүрәсе, 33-34 нче аятьләр).

Хәфиз ибн Кәсир رحمه الله үзенең "Тәфсир" китабында әйткән: *"Бу аять пәйгамбәребезнең ﷺ хатыннары аның гаилә әһелләреннән саналуын күрсәтә. Чөнки*

---

36 Мәккә белән Мәдинә шәһәрләре арасында су чыганагы янында агачлык [Ән-Нәүәүи "Шәрх Сахих Мөслим" 15/256], хәдистән күренгәнчә, пәйгамбәребез ﷺ бу урында ялга туктаган вакытта, сахабәләренә нәсыйхәт итеп, вәгазь биргән.

37 Пәйгамбәребез ﷺ монда Үлем фәрештәсен күздә тота, ягъни, тиздән үзенең вафат булачагы турында хәбәр бирә [Әл-Итьюби "Әл-Бәхрүл-Мүхыйт" 38/589].

38 Ягъни, бу мәсьәләнең мөһимлеген күрсәтеп, пәйгамбәребез ﷺ ахыргы җөмләсен өч мәртәбә кабатлаган! [Әл-Итьюби "Әл-Бәхрүл-Мүхыйт" 38/590].

*аять алар сәбәпле иңгән. Ә инде аять берәр кем аркасында иңгән икән, әлбәттә бу, иң беренче чиратта, аңа кагыла”.* [39]

Шулай ук, мөэминнәрнең әмире хәлиф Гәли ибн Әби Талиб, Аллаһ илчесенең ﷺ кызы Фәтыймә, аларның уллары әл-Хәсән һәм әл-Хүсәйн пәйгамбәребезнең ﷺ гаилә әһелләреннән булып торалар, Аллаһ Тәгалә алардан разый булсын! Имам Мөслим “Сахих” хәдисләр җыентыгында Гаишәдән رضي الله عنها хәдис китерә: бервакыт иртән пәйгамбәребез ﷺ чыккан, аның өстендә кара төстәге йоннан плащ булган, шулчак аның янына Гәлинең улы әл-Хәсән килгән һәм пәйгамбәребез ﷺ аны үзенең плащы астына керткән, аннан әл-Хүсәйн килгән һәм ул да плащ астына кергән. Аннан Фәтыймә килгән һәм пәйгамбәребез ﷺ аны да үзенең плащы астына керткән. Аннан Гәли килгән һәм пәйгамбәребез ﷺ аны да үзенең плащы астына керткән. Шуннан соң, пәйгамбәребез ﷺ Аллаһның: **“Йә рәсүлнең гаилә әһелләре, Аллаһ сездән гөнаһларны күтәрүне вә сезне кимчелекләрдән пакъләүне телидер”** – дигән сүзләрен укыган.

---

[39] Күрәбез, кадерле укучым, пәйгамбәребезнең ﷺ гаилә әһелләренә, иң беренче чиратта, аның хөрмәтле хәләл җефетләре керә. Бу аять аларны гаилә әһелләре исемлегеннән чыгаручы шигыйларга карата инкяр итү булып тора.

**Әүлияләр белән булучы гадәттән тыш хәлләргә карата дөрес инану.**

Сөннәт һәм Җәмәгать әһелләренең игътикадыннан – Аллаһ Тәгаләнең әүлияләре белән очрый торган гадәттән тыш хәлләргә (кәрамәт) инану тора. Бу кәрамәт очраклары күп юллар белән тапшырыла һәм Аллаһның якын коллары белән килеп чыга.

Әүлияләр кем дигәндә, Сөннәт һәм Җәмәгать әһелләре "вәли" ("әүлия" сүзенең берлек саны) дип, шәригатьтә кушылганны үтәүче һәм тыелганнан тыелучы кешене атыйлар. Аллаһ Тәгалә әүлияләрне сыйфатлап әйтте: **"Әлбәттә, Аллаһның әүлияләренә һич куркыныч юк һәм алар көенмәсләр. Алар иман китерделәр һәм тәкъвалы булдылар".** ("Йуныс" сүрәсе, 62-63 нче аятьләр). Ягъни, әүлиялек – иман һәм тәкъвалык аша була икән.

Ә инде "кәрамәт" сүзе нәрсәне аңлата дигәндә – бу ниндидер гадәттән тыш могҗизалы вакыйганы белгертүче сүз, моны Аллаһ Тәгалә Үзенең әүлиясе аша күрсәтә, диненә яки дөньялыгына ярдәм йөзеннән. Әмма, кәрамәт – пәйгамбәр-рәсүлләрнең могҗизалары дәрәҗәсенә җитми.

Мисал өчен, кайбер әүлияләр белән очраган вакыйгаларны санап узыйк: мәсәлән, "Кәһф" сүрәсендә тау куышындагы егетләр кыйссасы; Гайсә пәйгамбәрнең анасы Мәрьям янында җәй көнендә кышкы җилек-җимешләр, ә кышын – җәйгеләре булуы, яки, аның финик пальмасы янына килеп, Аллаһның кушуы буенча, шул агачның кәүсәсен селкетеп, яшь һәм сусыл финик җимешләре коелып төшүе; "әл-Бәкъара" сүрәсендә Аллаһ Тәгаләнең бер кешене йөз елга вафат итеп, кирегә терелтүе; Аллаһка күп гыйбадәт кылучы Җүрайҗ кыйссасы; тау куышына кереп, керү юлын олы таш җимерелеп төшеп каплаган Бәнү Исраил халкыннан өч кеше вакыйгасы; һәм, шулай ук, галимнәр арасында билгеле, Көрьән, дөреслеге расланган хәдисләр, сәләфләр һәм алардан соң килүчеләр тарафыннан исбатланган күп төрле башка мисаллар.

Әүлияләрнең кәрамәте бу өммәттә Кыямәт көненә кадәр булачак һәм күренәчәк. Чөнки аның сәбәбе – иманлы һәм тәкъвалы булып Аллаһка якын булу, ә мондый сыйфатлы кешеләр Кыямәт көненә хәтле булыр.

Әгәр дә, берәр кем шундый гадәттән тыш хәл белән килә икән, бу аның берәр начарлыкка катышы булмаганлыгын һәм Аллаһның якын әүлиясе булуын бары шул очракта гына күрсәтә, әгәр дә аның гамәлләре Көрьән һәм Сөннәткә туры килеп, аларга тыштан да һәм эчтән дә иярүче булса гына. [40]

Аллаһка якын кешеләрнең фәзыйләте турында хәдис тә китерик, имам әл-Бохари үзенең "Сахих" хәдисләр җыентыгында Әбү Һүрайрадан رضي الله عنه риваять итә: "*Аллаһ илчесе ﷺ әйтте:* ***"Чынлыкта, Аллаһ Тәбәракә вә Тәгалә әйтә:*** **"Кем миңа якын булган кешегә карата дошманлык күрсәтә, шуңа мин сугыш игълан итәм"** –дигән.

---

40 Шуңа күрә, имам әш-Шәфигиның رحمه الله мәшһүр сүзләре билгеле: *"Әгәр дә сез су өстеннән атлаучы яки һавада ирекле рәвештә очып баручы кешене күрәсез икән, гамәлләрен Көрьән һәм Сөннәт белән чагыштырып карамыйча, аның белән алданмагыз"* – дигән. ["Тәбәкъат әш-шәфигийя", 63].

## **Мөселманнарның дәүләт башлыклары каршында булган вазифаларга карата дөрес инану.**

Сөннәт һәм Җәмәгать әһелләренең игътикадыннан – Аллаһ Тәгалә мөэмин-мөселманнарга аларның өсләрендә торган дәүләт башлыкларына буйсынуны әмер иткәнен тану тора, әлбәттә, Аллаһ Үзе тыйган эшләрдә буйсынудан кала. [41]

Мөэминнәр үзләренә пәйгамбәребезнең ﷺ Гүбәдә ибн әс-Самит رضي الله عنه исемле сахабә аша тапшырылган сүзләрен игътикад итеп алганнар: ***"Җиңеллектә дә, авырлыкта да, ошаса да, ошамаса да, сиңа тиешлене бирмәсәләр дә, малыңны [хаксызга] ашасалар да һәм аркаңны суктырсалар да – [дәүләт башлыгын] тыңла һәм аңа буйсын, бары тик, гөнаһлы эшләрдә генә [буйсынма]"*** – дип әйткән пәйгамбәребез ﷺ. Хәдисне имам ибн Хиббән үзенең "Сахих" китабында яхшы юл белән китерә, ә аның асылы имам әл-Бохариның һәм имам Мөслимнең "Сахих" хәдисләр җыентыкларында урын алган.

Сөннәт һәм Җәмәгать әһелләре мөселманнарның дәүләт башлыкларына каршы чыгышларның тыелганлыгына инанганнар, хәтта алар туры юлдан авышкан һәм золымлык кылучы булсалар да, иллә-мәгәр Аллаһтан дәлиле булган ачыктан-ачык көферлеккә төшмәсләр. Пәйгамбәребез ﷺ әйткән: ***"Иң хәерле башлыкларыгыз – сез аларны яратучы һәм алар да сезне яратучы, алар сезнең өчен дога кылучы һәм сез дә алар өчен дога кылучылары; ә инде, иң начар башлыкларыгыз – сез аларны яратмаучы һәм алар да сезне яратмаучы, сез аларны ләгънәт кылучы һәм алар да сезне ләгънәт кылучы булганнары"*** – дигән. Шуннан, пәйгамбәребездән ﷺ сораганнар: *"Йә Аллаһ илчесе! Андыйларына каршы кылыч белән чыгыйкмы әллә?"* Пәйгамбәребез ﷺ: ***"Юк, әгәр дә алар сезнең арагызда намаз укучы булсалар, [чыкмагыз]. Әгәр башлыкларыгыздан сезгә ошамаган берәр нәрсә күрсәгез, аларның бу гамәлләрен яратмагыз, әмма кулыгызны буйсынудан алмагыз"*** – дип җавап биргән.

Берәркем мөселманнарның [законлы башлыклары булган] җәмәгатенә каршы чыга икән, Аллаһ, бу дөньяда да һәм ахирәттә дә, ул кешегә аның җинаятенә тәңгәл килгән җәза әзерләде, [хәдисләрдән күренгәнчә]:

- кем башлыкка буйсынудан баш тартып, җәмәгатькә каршы чыга икән, шул Җаһилият үлеме белән вафат булыр;
- шулай ук, гөнаһы зур булуы сәбәпле, мондый кеше турында хәтта сорашмыйлар да;
- Аллаһ каршында аклану өчен, Кыямәт көнендә бу кешенең бернинди дә дәлиле булмас;

---

[41] Аллаһ Тәгалә тарафыннан буйсынырга әмер ителгән дәүләт башлыклары кемнәр була дигәндә, аларның кайбер шартларына карата факиһләр бертавышта булды, ә кайберләрендә бераз фикер каршылыклары бар. Мисал өчен, аларның Ислам динендә, балигъ, үз акылында, ир-ат булулары, сугыш һәм сәясәт алып барырга, җәза хөкемнәрен башкарырга һәм өммәтне якларга сәләтле булулары, кол булмаулары, хис-тойгылары һәм тән әгъзалары җитәкче ролен башкарырга комачау китермәслек сәламәт булулары – бу шартларга карата галимнәр бердәм. [Тулырак мәгълүмат өчен "Тәфсир әл-Къуртуби" 1/404-405, "Мәүсүгәтүл-фикһия" 6/218-219 китапларын карарга була].

- шайтан һәрвакытта да мондый кешенең юлдашы булыр;
- [дәүләт башлыгына бу кешеләргә каршы сугыш алып бару рөхсәт ителгән].

Шулай ук, Сөннәт һәм Җәмәгать әһелләре шуңа инанганнар – мөселманнарның дәүләт башлыклары өчен хәерлек һәм иминлек сорап дога кылу мактаулы һәм расланган гамәл, һәм Сөннәт әһеленнән булган кешенең билгесе. Имам әл-Бәрбәһәри үзенең “Сөннәт шәрхе” китабында әйткән: *“Әгәр дә син мөселманнарның дәүләт башлыгына каршы дога кылучыны күрсәң, бел, бу – үз нәфесенә ияртүче кеше; ә инде, дәүләт башлыгына хәерлек сораган берәр кемне ишетсәң, бел, бу – Сөннәт әһеле, ин шәә Аллаһ. Әл-Фудайл ибн Гыяд әйткән: “Әгәр дә мин [кабул булачак] бер догам бар икәнен белсәм, аны, һичшиксез, дәүләт башлыгы өчен кылыр идем. Безгә алар өчен хәерлек сорап дога кылырга әмер ителде, аларга каршы түгел, хәтта, туры юлдан авышучы һәм золымлык кылучы булсалар да. Чөнки аларның хактан авышулары һәм золымлыклары – үзләренә һәм мөселманнарга каршы, һәм хәерлекләре дә – үзләре һәм мөселманнар өчен”* – дигән.

Шулай ук, имам әс-Сабуни үзенең “Сәләфләрнең һәм хәдис тарафдарларының гәкыйдәсе” китабында әйткән: *“[Сөннәт һәм Җәмәгать әһелләре дәүләт башлыклары өчен] төзәлү, тәүфыйк һәм хәерлек сорауны хуп дип күрәләр”* – дигән.

Ә аларны сүгү һәм хурлау шәригатьтә пәйгамбәребезнең ﷺ олы сахабәләренең бердәм сүзе белән тыелган. Әнәс ибн Мәлик رضي الله عنه әйткән: *“Пәйгамбәребезнең ﷺ олы сахабәләре безне тыйдылар һәм әйттеләр:* ***“Дәүләт башлыкларыгызны сүкмәгез, алдаламагыз һәм нәфрәт күрсәтмәгез, Аллаһтан куркыгыз һәм сабыр булыгыз. Чынлыкта, [Аллаһның] әмере якындыр”.*** Ибн Әби Гәсыйм үзенең *“*Әс-Сөннәт” китабында һәм башкалар китерәләр.

**Дини мәсьәләләрдә низаг һәм тартышуның тыелганлыгы.**

Сөннәт һәм Җәмәгать әһелләре дин мәсьәләләрендә низагка керү һәм тартышуны тыялар, чөнки моны пәйгамбәребез ﷺ үзе тыйган.

Имам әл-Бохариның һәм имам Мөслимнең "Сахих" китапларында пәйгамбәребездән ﷺ хәдис килә, ул әйткән: ***"Көрьәнгә карата калебләрегез бердәм булганда аны укыгыз, ә инде низаглаша башласагыз, аннан торып китегез"*** – дигән.

Шулай ук, имам Әхмәднең "әл-Муснәд" һәм имам ибн Мәҗәһнең "әс-Сүнән" китапларында, асылы имам Мөслимнең "Сахих"ында булучы, Гәбдуллаһ ибн Гәмердән хәдис килә: "Бервакыт пәйгамбәребез ﷺ [өеннән] чыккан да, сахабәләрнең тәкъдир мәсьәләсендә бәхәсләшкәннәрен күргән. Шулчак пәйгамбәребезнең ﷺ ачуы чыккан, хәтта йөзенә гранат орлыгын сыткannar кебек тоелган, һәм әйткән: ***"Сезгә шул әмер ителдеме? Яки сез шуның өчен бар кылындыгызмы? Көрьәннең бер өлешен икенчесенә орыр өчен?! Сезгә хәтле булган өммәтләрне шушы һәлакәткә китерде"*** – дигән.

Шулай ук, диндә төрле низаглар һәм тартышулар өммәткә Аллаһ Тәгаләнең бер җәзасы булуы турында хәбәр килә. Имам әт-Тирмизи һәм имам ибн Мәҗәһнең "әс-Сүнән" китапларында Әбү Үмәмә رضي الله عنه исемле сахабәдән хәдис җиткерелә, ул әйткән: "*Аллаһ илчесе ﷺ әйтте:* ***"Берәр кавем туры юлда булудан туктамады, бары тик, берберләре белән сүз көрәштерә башлагач кына адаштылар"*** – дигән. Аннан ул Аллаһның сүзләрен укыган: **"Алар сиңа бу чагыштыруны синең белән сүз көрәштерер өчен генә китерделәр, алар тартышучы кавемдер"** ("Әз-Зүхруф" сүрәсе, 58-нче аять).

Имам Әхмәд رحمه الله әйткән: *"Бездә Сөннәтнең [бер] нигезе булып, пәйгамбәребезнең ﷺ сахабәләре юлына ныклап ябышу һәм алар артыннан ияру тора. Бидгатьләрне калдыру да [аның бер нигезеннән], [чөнки] һәрбер бидгать – адашудыр. Үз теләкләренә иярүчеләр белән бергә утырмау һәм алар белән сүз көрәштермәү, дин мәсьәләләрендә низаг һәм тартышуларны калдыру, шулай ук, Сөннәт нигезләреннән"* – дигән.

Монда "низаг, тартышу" дигән сүз астында: дөрес булмаган һәм ялган дәлилләр аша бәхәсләшү; яки хаклык ачылганнан соң да сүз көрәштерүне калдырмау; яки бәхәсләшүченең үзе дә белмәгән һәм аңламаган мәсьәләдә тартышуы; яки Көрьәннең ачык мәгънәле аятьләрен калдырып, мәгънәсе бөтен кешегә дә ачык булмаган аятьләре аша сүзгә керү; яки начар ниятләр белән сүз тартышу һәм бәхәснең башка шундый төрләре күздә тотыла.

Әгәр дә инде, бәхәс – гыйлем иясе тарафыннан, дөрес ният һәм яхшы әдәб белән, хаклыкның төбенә төшү һәм аны бәян итү өчен алып барылса, мондый очракта бу күркәм бәхәс була. Аллаһ Тәгалә әйтте: **"Раббың юлына хикмәт һәм яхшы вәгазь белән чакыр, һәм алар белән сүзеңне иң күркәм рәвештә алып бар".** ("Ән-Нәхел" сүрәсе, 125-нче аять).

Аллаһ Тәгалә, шулай ук, әйтте: **"Китап әһелләре белән бары күркәм юл белән генә бәхәсләшегез".** ("Әл-Гәнкәбүт" сүрәсе, 46-нчы аять).

Шулай ук: **“[Имансызлар] әйттеләр: “Йә Нух, син безнең белән бәхәсләштең һәм бәхәсләшүеңне бик күп кылдың, әгәр дөрес сөйләүчеләрдән булсаң, вәгъдә кылган газабыңны өстебезгә китер”.** (“Һүд” сүрәсе, 32-нче аять).

Аллаһ Тәгалә Көръәндә, хак булган, төрле бәхәсләрне китерә: Ибраһимның عليه الصلاة و السلام үзенең кавеме белән, Мусаның عليه الصلاة و السلام Фиргавен белән, һәм башкалар. Хәдисләрдә Әдәм һәм Мусаның عليهما الصلاة و السلام бер-берсе белән бәхәсе китерелә. Шулай ук, тәкъва сәләфләрдән дә күп төрле дискуссияләр тапшырыла. Әлбәттә, монда – гыйлемгә, дөрес нияткә, [пәйгамбәрләр юлына] иярүгә һәм яхшы әдәбкә нигезләнгән күркәм юл белән бәхәсләшү турында сүз бара.

**Үз теләкләренә иярүчеләр белән бергә утыру хакында кисәтү.**

Сөннәт һәм Җәмәгать әһелләре, катгый рәвештә, үз теләкләренә иярүче бидгать әһелләре белән бергә йөрүне һәм утыруны тыялар. Чөнки, монда Аллаһның әмеренә каршы килү һәм аларны ярату билгесе бар. Мондый кешеләр белән бергә утыручы үзен аларның адашуларына авышу һәм ялганнарына иярү астына куя.

Имам ибн Тәймийә رحمه الله әйткән: *"Кешене үз теләгенә иярүче бидгать әһеленнән санауга китерә торган бидгать дигәндә, Сөннәтне белүче гыйлем ияләре тарафыннан Көрьәнгә һәм Сөннәткә каршы килүе расланган билгеле бидгать күздә тотыла. Мисал өчен хаүәриҗ, рафидый, кадарий һәм мүрҗигыйлар кебек"* – дигән.

Аллаһ Тәгалә әйтте: **"Әгәр аятьләребезне яманлап сөйләүчеләрне күрсәң, хәтта башка сүзгә күчкәннәренә чаклы, алар янында торма, кит! Вә әмма шайтан сиңа моны оныттырса, исеңә төшү белән кит, залимнәр янында булма".** ("Әл-Әнгәм" сүрәсе, 68-нче аять).

Гәбдуллаһ ибн Гәббәс әйткән: *"Бу аятькә, Кыямәт көненә чаклы, дингә төрле яңалык кертүче һәм бидгать әһеле булган һәрбер кеше керә"* – дигән. Бу риваятьне имам әл-Бәгъаүи үзенең "Тәфсир"ендә китерә.

Имам ибн Җәрир әт-Табари әйткән: *"Бу аятьтә барча батыл әһелләре белән бергә утыруны тыюга карата ачык күрсәтмә бар, аларның нинди генә төрдән булуларына карамастан – бидгать яки гөнаһ әһелләре булсынмы, үзләренең батылларына бирелгән вакытта [алардан ерак булырга кирәк]"* – дигән.

Гәбдуллаһ ибн Гәббәс: *"Үз теләкләренә иярүчеләр белән бергә булма, алар белән бергә утыру калебкә сырхау китерә"* – дип әйткән.

* * *

Аллаһка барча мактау булсын! Шушы урында, Аның рәхмәте һәм тәүфыгы белән, "Һәрбер мөселманга тиешле дөрес инанулар" дип исемләнгән китабыбыз тәмам булды. Аллаһ Тәгаләдән әлеге эшебезне ихластан Аның Йөзе өчен үтәлгән, пәйгамбәребезнең ﷺ Сөннәтенә туры килгән һәм мөселманнар өчен файдалы булуын сорыйбыз!

Мөхәммәд пәйгамбәргә, аның пакъ гаилә әһелләренә, Аллаһ тарафыннан сайланылган сахабәләренә һәм Кыямәт көненә кадәр, ихласлы рәвештә, аларның юлына иярүчеләргә Аллаһның мактавы, сәламе һәм бәрәкәте булсын!